СОҢГЫ ТУКТАЛЫШ

Читтән кайткан мәетләргә авыл зиратында урын бармы?

> 15

САБЫЙ КӨЧЕ

Ун яшьлек Илназ куллы булыр өчен тырыша

> 17

ВАДИМ ЗАХАРОВ:

«Моңлы җырчылар авылда туа»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 134 (29101) | Җомга | 15 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

tatarstan.ru

БЕЗНЕҢ КӨЧ – БЕРДӘМЛЕКТӘ

ТАТАРСТАН РӘИСЕ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫ

«Безне сындырып булмый!» Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына еллык Юлламасында бу сүзләр кызыл җеп булып узды. Республиканың эчке һәм тышкы хәле турында сөйләгәндә Рәис махсус хәрби операция темасына берничә тапкыр тукталды. Мәртәбәле чарага хәрбиләр һәм солдатларга ярдәм күрсәтүчеләр дә чакырулы иде. Аларны бөтен зал аягүрә басып алкышларга күмде. Рөстәм Миңнеханов Татарстанны илнең терәк төбәге дип атады. Казанышларыбызның нигезендә исә татарстанлыларның республикага тугрылыгы һәм Ватанга мәхәббәте ятуын әйтте. Киләсе ел Татарстанда «Фәнни-технологик үсеш елы» дип игълан ителде.

> 2–7

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

Татарстан Республикасында 2024 елны Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итү турында

Татарстан Республикасында киләчәктә фән һәм технологияләрне үстерү, республиканың социаль-икътисадый үсешенең мөһим бурычларын хәл итүдә аларның ролен көчәйтү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында 2024 елны Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 14 сентябрь
№ 639

Юллама – саннарда

6126 сүз >> **1 сәгать 10 минутлык** чыгыш

ИҢ ЕШ КАБАТЛАНГАН 5 СҮЗ

Республика >> **82** / Татарстан >> **40**

Үстерү >> **31** / Ярдәм >> **36** / Россия >> **29**

БЕЗНЕҢ КӨЧ – БЕРДӘМЛЕКТӘ

ТАТАРСТАН РӘИСЕ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫ

Хөрмәтле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары һәм утырышта катнашучылар!
Кадерле татарстанлылар!
Татарстан Республикасы үзенең тотрыклы үсешен дәвам итә. Аның нигезендә – иҗтимагый-сәяси ныклык, милләтара, конфессияара тынычлык һәм гражданлык татулыгы. Бу – безнең төп байлыгыбыз.


tatarstan.ru

Татарстан Республикасы – бүгенге көндә Россия Федерациясенең терәк субъекты, икътисадый уңышларга ирешә торган алдынгы төбәк. Барлык буын татарстанлыларның фидакарь хезмәте, республикабызга тугрылыгы, Ватанга мәхәббәте казанышларыбыз нигезен тәшкил итә. Бу юлны, көчле Россиянең үсешенә үзебездән өлеш кертеп, эзлекле рәвештә дәвам итү – безнең уртак бурычыбыз.

Илебез очраган җитди кыенлыклар тормышыбызның барлык өлкәләренә йогынты ясады. Шуңа да карамастан, без аларны җиңә барабыз.

Безнең ихтыяр көчебезне сындыру мөмкин түгел – без моны раслadык!

Россия Федерациясе Президенты, Югары Башкомандующий Владимир Владимирович Путинның ныклы курсы нәтиҗәсендә дәүләтнең хәрби-оборона көче арта бара, икътисадта тотрыклылык саклана, җәмгыятьтә бердәмлек арта.

Һәр көн саен солдатларыбыз һәм офицерларыбыз фронтның алгы сызыгында үз-үзләрен аямыйча хәрби бурычларын үти. Кораллы Көчләр сафларында, Россия милли гвардиясе, Эчке эшләр министрлыгы һәм Федераль куркынычсызлык хезмәте бүлекчәләрендә хезмәт иткән татарстанлылар үз алларына куелган бурычларны намус белән үти. Тугыз татарстанлыга Россия Федерациясе Герое исеме бирелде. Меңнән артык сугышчыбыз орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

Бүген залда – махсус хәрби операциядә катнашучылар да бар.

Биредә легендар «Алеша» танкы экипажы командиры, Россия Герое Рәсим Баксиковны күрүемә шатмын.

Сезнең һәрберегез – каһарманлык, Ватанга тугрылыклы хезмәт итү үрнәге. Сезгә һәм махсус хәрби операциядә катнашкан һәркемгә сезнең аша ихлас рәхмәт сүзләрен җиткерәбез! Без сезнең белән горурланабыз!

Кадерле ватандашлар!

Ватан өчен гомерен корбан иткән каһарманнарның исемнәре безнең хәтеребездә мәңге сакланачак. Аларның батырлыгы һичкайчан онытылмаячак.

Һәлак булганнарның якты рухын бер минутка тын калып искә алыйк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Махсус хәрби операциянең беренче көннәреннән үк татарстанлылар фронтның алгы сызыгындагы ватандашларыбызга, шулай ук шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә актив ярдәм күрсәтә. Республикадан җибәрелгән гуманитар ярдәмнең гомуми күләме бүгенге көнгә 4 мең тоннадан артып китте. Моннан тыш, без Татарстанда формалаштырылган барлык бүлекчәләрне кирәкле корал һәм техника белән тәэмин итәбез.

Предприятиеләребез һәм оешмаларыбыз, муниципалитетларыбыз һәм депутатларыбыз, «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!», «Халык фронты» һәм «Игелекле Казан» хәрәкәтләре, республика ДОСААФы, дини оешмалар, дистәләрчә волонтерлар берләшмәләре – бу эштән берсе дә читтә калмады.

Фронтның алгы сызыгына һәм яңа территорияләргә шәхсән барып йөрүче предприятие җитәкчеләренә, шәһәр һәм район башлыкларына, депутатларыбызга, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Евгений Анатольевич Варакинның бүгенге көндә Лисичанскида һәм Рубежноеда четерекле шартларда эшләүче командасына аеруча зур рәхмәт белдерергә телим. Алар арасында шул исәптән төзүчеләребез, медицина хезмәткәрләре, социаль хезмәткәрләр һәм волонтерларыбыз да бар! Бик зур рәхмәт сезгә!

Уртак эшкә үзләреннән хәл кадәренчә өлеш керткән гражданнарыбыз турында аерып әйтеп узасым килә. Республикада мондый кешеләр күп. Бүген залда безнең белән Бөгелмә районыннан үз акчасына УАЗ автомобиле сатып алып, аны сугышчыларыбызга тапшырган Таисия Балаева, Әлмәт районыннан тактик корал элементларын үзлегеннән җитештерүче Илдар Зарипов, Балык Бистәсе районыннан махсус хәрби операция зонасына дистәләгән генераторлар, мичләр һәм җылылык өчен төрле җайланмалар әзерләп озаткан Айдар Гыймадиев, Чаллыдан республиканың махсус хәрби операция зонасындагы барлык бүлекчәләренә берничә миллион сумлык гуманитар ярдәм озатуны җайга салган Светлана Гурлева. Сезгә һәм барлык битараф булмаган гражданнарга без бик рәхмәтле!

Махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаиләләре, аеруча һәлак булган сугышчыларның гаиләләре турында кайгырту гаять мөһим.

Республикада төрле яклап ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру, балалар бакчаларында урыннар бирү, атааналарны түләүдән азат итү, мәгариф оешмаларында бушлай кайнар ризык белән тукландыруны булдыру, шулай ук социаль, юридик һәм психологик ярдәм күрсәтү эше җайга салынды.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның эш урыннарын һәм аларга хезмәт хакы түләүне саклап калу турында карар кабул иткән предприятиеләр җитәкчеләренә без бик рәхмәтле.

Тагын бер кат әйтәм: махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре тормышындагы бер генә кыен хәл дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Килеп туган мәсьәләләрне тиз арада һәм сыйфатлы хәл итү, «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының республикада быел төзелгән филиалына мөмкин булганча ярдәм күрсәтү – барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының, предприятиеләребезнең, оешмаларыбызның бурычы.

Медиа-киңлек чын мәгънәсендә сугыш кырына әйләнде. Россиягә каршы көчле мәгълүмати сугыш җәелдерелде. Бу очракта без журналистларның һәм авторларның һөнәри осталыгын, үз эшен яхшы белүен, битараф булмавын, граждан буларак актив позициядә торуын, халыкка хак һәм объектив мәгълүмат бирүен каршы куя алабыз. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең абруена тап төшерү, республикада тотрыклы хәлне какшату омтылышларын киләчәктә дә катгый тыярга кирәк. Массакүләм мәгълүмат чараларын, яңа мәгълүмат чараларын бу эшкә тулысынча тарту зарур.

Көнбатыштан илебез яшьләренә тискәре идеологик йогынты ясау омтылышлары элеккечә дәвам итә. Традицион рухи хәзинәләрне юкка чыгаруга, тарихи хәтерне бозып күрсәтүгә аеруча басым ясала.

Әлеге шартларда ватанпәрвәрлек тотрыклылыгыбызның какшамас нигезен тәшкил итәргә тиеш. Массакүләм мәгълүмат чараларына нәкъ менә шушы фикерләрне тарату мөһим, мәдәният һәм сәнгать әһелләренең әсәрләре шуларга нигезләнергә тиеш.

Бу эштә балаларның һәм яшүсмерләрнең «Яшь армия», «Зур тәнәфес» дигән иҗтимагый берләшмәләренә, «Авангард» хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча укыту-методик үзәкләренә, волонтерлык отрядларына һәм оешмаларына зур роль бирелә.

Илебез Президенты башлангычы белән «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия балалар һәм яшьләр оешмасы төзелде. Аның төп бурычлары – яшь буында илебез белән горурлану, Ватанны ярату хисе тәрбияләү, тарихи хәтерне саклау.

Татарстан бу эштә актив катнаша: барлык муниципалитетларда җирле һәм башлангыч бүлекчәләр төзелде, бик күп яшьләр катнашында чаралар уздырыла.

Шунысын да әйтергә кирәк: яшь буынга тәрбия бирү – бер генә көнлек эш түгел. Балалар бакчаларының өлкән

төркемнәрә тәрбиячеләренә, мәктәпләрдә сыйныф җитәкчеләренә һәм урта махсус уку йортлары һәм югары уку йортларының хезмәткәрләренә зур җаваплылык йөкләнә.

«Беренчеләр хәрәкәте»нең барлык дәрәҗәдәге җитәкчеләренең игътибарын бу очракта формаль эш итәргә ярамавына юнәлтәм. Яшь буынны тәрбияләүгә ихлас мөнәсәбәт булганда гына, без киләчәккә ышаныч белән карый алачакбыз.

Һичшиксез, балада ватанпәрвәрлек хисе, рухи-әхлакый хәзинәләргә тугрылык, иң беренче чиратта, гаиләдә тәрбияләнә. Гаиләнең әһәмияте бәяләп бетергесез. Нәкъ менә гаиләдә халкыбызга хас булган җиргә, туган йортка мәхәббәт, тугрылык һәм үзара хөрмәт, эш сөючәнлек һәм җаваплылык кебек сыйфатларга нигез салына.

Бүген без залга Ватанны саклаучылар династияләрен – алардагы берничә буын үз язмышын Ватанны саклауга багышлаган гаиләләрне чакырдык. Мондый гаиләләр – республикабызның горурлыгы һәм даны. Соколовлар, Сибгатуллиннар һәм Тульчанскийлар династияләре – шундыйлардан.

Рәхмәт сезгә!

Республикада мондый гаиләләр күп. Сезгә һәм республикадагы барлык Ватанны саклаучылар гаиләләренә иминлек һәм уңышлар телим!

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Тарихи хәтерне саклау – безнең изге бурычыбыз. Быел гына да республикада 22 Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Героена, шул исәптән махсус операциядә катнашучыларга һәйкәлләр, бюстлар һәм мемориаль такталар куелды. Ватан Геройлары истәлеген мәңгеләштерү эшен, һичшиксез, киләчәктә дә дәвам итәчәкбез. Республика Хөкүмәтенә, Казан мэриясенә башкаланың Җиңү паркында махсус хәрби операциягә багышланган мемориаль зона ачу турындагы тәкъдимнәр әзерләүне йөклим.

2025 елда илебез Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итәчәк. Хөкүмәтка, шәһәр һәм район башлыкларына инде хәзердән үк юбилей датасын бәйрәм итүне оештыру эшен башларга кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Киләсе елның язында Россия Федерациясе Президентын сайлау узачак. Бүген илебез читтән янаган куркынычларга каршы тора һәм алар җәмгыятебезнең берләшүенә тагын бер этәргеч булыр, ә татарстанлылар сайлау кампаниясе барышында югары активлык һәм илкүләм лидерыбызның хәзерге курсына теләктәшлек күрсәтерләр дип ышанам.

Киләсе елның сентябрендә республика Дәүләт Советының җиденче чакырылышы сайланачак. Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин рәислегендәге Дәүләт Советы, тирәнтен уйланган дөрес карарлар кабул итеп, республиканың һәм аның гражданнарының мәнфәгатьләрен һәрчак яклый килә.

Хөрмәтле депутатлар! Хезмәтегез өчен зур рәхмәт!

Хөрмәтле депутатлар!

Татарстанда традицион төстә милләтләр һәм диннәр арасында тынычлык һәм гражданнар арасында татулык саклана.

Быел «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең динара багланышлар форматындагы эшчәнлеге кысаларында Мәскәү һәм бөтен Русия Патриархы Кирилл катнашкан чаралар, Татар дин әһелләренең XIII Бөтенроссия форумы, Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам динен кабул итү көнен бәйрәм итү чаралары, шулай ук Мәрьям Ана Казан иконасы табылуга багышланган традицион чаралар рухи берләшү һәм теләктәшлек шартларында узды.

Ноябрьдә республика башкаласында Татарстанның бишенче православие җәмәгатьчелеге форумы булачак.

Гомумән алганда, республиканың милләтара һәм динара багланышларны үстерү мәйданчыгы дигән статусын раслауны дәвам иттерергә кирәк.

Соңгы елларда Татарстанда тарихи-мәдәни мирасны саклау юнәлешендә, аеруча «Яңарыш» фонды эшчәнлеге кысаларында зур эшләр башкарыла.

Республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында алып барыла торган эш милли-мәдәни төрлелекне үстерүгә ярдәм итә.

Безгә киләчәктә дә мәдәни байлыгыбызның, ата-бабаларыбыз турындагы хатирәләрнең саклануы, һәр халыкның үзенчәлеге киләсе буыннарда да дәвам итсен өчен уртак тырышлык куярга кирәк. Шул рәвешчә генә без ата-бабаларыбыздан мирас булып калган кабатланмас мәдәни үзенчәлегебезне саклый алачакбыз. Бу эштә, һичшиксез, мәдәният һәм сәнгать әһелләренә мөһим роль бирелә.

Яшь буын өчен мәдәни үсешне генә түгел, бәлки белем һәм тәрбия бирү юнәлешен дә игътибар үзәгендә тотарга кирәк. Сүз мәгариф һәм тәрбия программаларына «Халык традицияләре» модулен кертү, системалы нигездә халык һөнәрчелеге буенча осталык дәресләре, курслар уздыру, балалар өчен укыту-күрсәтмә әсбаплар булдыру турында бара.

Казанда Халык сәнгать һөнәрчелеген, кәсепчелеген һәм декоратив-гамәли сәнгатен торгызу, саклау, өйрәнү һәм үстерү үзәге ачылу бу юнәлештә җитди ярдәм булырга тиеш.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Татарстан Республикасы, традицион рухи хәзинәләргә, тарихи-мәдәни мираска тугры калып, дөньяда гадел багланышлар урнаштыруны яклый килеп, чит ил партнерлары белән халыкара хезмәттәшлекне үстерүне дәвам иттерә.

Дәүләт башлыгы тарафыннан билгеләнгән өстенлекләрнең берсе – ислам дөньясы белән үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерү.

Бу юнәлештә Kazan-Forum халыкара икътисадый форумы нәтиҗәле мәйданчыкка әверелде. Уздырылган чаралар ил җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнде. Быел анда сиксәннән артык чит ил вәкиле катнашты. Бу исә Россиянең дөнья белән бәйләнешләрен өзү мөмкин түгеллеген тагын бер кат раслады. KazanForumны киләсе елда югары дәрәҗәдә уздыруны тәэмин итәргә кирәк.

Моннан тыш, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән төрле юнәлешләрдә, шул исәптән дөнья күләмендә яшьләргә кагылган гамәлләр, фән, мәдәният, мәгариф, спорт даирәсендә, шулай ук хәләл тормыш рәвеше алып баруга шартлар тудыру өлкәсендә хезмәттәшлекне дәвам иттерү зарур.

Ислам илләреннән инвестицияләр җәлеп итү өчен Партнерлар (ислам) финанслары буенча федераль законны гамәлгә ашыру мөһим юнәлеш булып тора. Татарстан Республикасыннан сайланган Дәүләт Думасы депутатларына аны эшләүдә һәм кабул итүдә актив катнашканнары өчен рәхмәт белдерергә телим.

Сынау төбәге буларак, безгә илебездә партнерлар финансларының файдаланыла башлавы өчен уңайлы хокукый шартлар булдыру тәҗрибәсен сыйфатлы итеп уздыруны тәэмин итәргә кирәк. Ислам банкингы буенча белгечләр әзерләү эшен оештыру зарур. Моннан тыш, халыкка һәм бизнеска мәгълүмат бирү эшенә аерым игътибар бирү сорала. Монда республика мөселманнарының Диния нәзарәтенә төп роль бирелә.

Илебез Президенты 2024 елда Казанда егермедән артык ил лидеры катнашачак БРИКС һәм БРИКС+ дәүләт башлыклары саммитын уздыру турында указга кул куйды. Безнең өчен бу зур дәрәҗә булу белән бергә, бик зур җаваплылык та. Саммит кысаларында бик күп чаралар, шул исәптән мультиспорт чаралары – БРИКС уеннары узачак. Безнең алда куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм кунаклар кабул итүгә әзерлек буенча җитди эшләр тора. Республика оештыру комитетына федераль дәрәҗәдәге хезмәттәшләре белән берлектә аны координацияләүне оештырырга кирәк.

Ватандашлар белән хезмәттәшлек республиканың тышкы элемтәләренең мөһим юнәлеше булып тора. Биредә төп эшне Бөтендөнья татар конгрессы башкара. Ул бөтен дөнья буенча татар милли-мәдәни оешмаларын берләштерә, төрле төбәкләрдә дәүләт органнары белән хезмәттәшлекне ныгыта. Конгресска милләттәшләр белән эшләү формаларын тагын да камилләштерү мөһим.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Республика икътисады, тулаем Россиядәге кебек үк, тышкы сынауларга бирешми һәм тотрыклы булып кала. Бу елның төп социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләрендә уңай динамика күзәтелә. Әлеге нәтиҗәләр күпчелектә алдагы елларда тупланган көч, федераль һәм республика күләмендә оператив төстә кабул ителгән ярдәм чаралары нәтиҗәсендә мөмкин булды.

Без илебез Президенты Владимир Владимирович Путинга, Россия Хөкүмәтенә вакытында кабул ителгән карарлары һәм башлангычларыбызга ярдәм күрсәтүләре өчен рәхмәтле.

Предприятиеләребез җитәкчеләренә аерым рәхмәт сүзләремне җиткерергә телим. Катлаулы шартларда сез җитештерү һәм хезмәт коллективларын саклап кала, аларның тотрыклы эшен тәэмин итә, ә иң мөһиме – яңа җитештерү һәм логистика бәйләнешләрен булдыра алдыгыз.

Алга таба да барлык тармак предприятиеләренең өзлексез эшен тәэмин итәргә кирәк. Министрлыкларның, ведомстволар, муниципалитетлар һәм депутатларның бурычы – бизнеска максималь ярдәм күрсәтү, һәр җитештерүченең сорауларына игътибар бирү, предприятиеләргә дәүләт тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм турында мәгълүмат бирү һәм аларның эшенә җитәкчелек итү.

Россия Президенты куйган бурычларның иң әһәмиятлеләреннән берсе – төп тармакларда технологияләр буенча бәйсезлеккә ирешү һәм җитештереп тәкъдим итү икътисады булдыру.

Татарстанда аны гамәлгә ашыруда актив катнашу өчен бөтен шартлар бар. Беренче нәүбәттә бу – алдынгы фәнни-тикшеренү һәм сәнәгать-җитештерү базасы.

Быел республика нефтьчеләре Татарстан нефть ятмаларын сәнәгать ысуллары белән үзләштерә башлауның 80 еллыгын билгеләп үтә. Бу елларда республика ятмаларыннан 3,5 млрд тонна «кара алтын» чыгарылды. Нефть сәнәгате предприятиеләре бүген дә республика икътисадының нигезен тәшкил итә.

«Татнефть» компаниясе үсеш стратегиясен эзлекле гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә нефть чыгару предприятиесеннән Россиянең вертикаль интеграцияләнгән эре компаниясенә әверелде. Аның составында нефть һәм газ чыгару, нефть һәм газ эшкәртү, нефть һәм газ химиясе, АЗС челтәрләре, композит кластеры, электр энергетикасы һәм башка бик күп тармаклар динамикалы үсә.

«Татнефть» компаниясенең уңышлы проектларының берсе – «ТАНЕКО» комплексы – 500 млрд сум күләмендә инвестицияләр кертелә торган, нефть чималын эшкәртү буенча югары технологияле заманча предприятие. Быел «ТАНЕКО»да нефть чималын эшкәртү күләме 18 млн тоннадан артып китәргә тиеш.

«СИБУР» компаниясе республика территориясендә эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итә. «ЭП-600» олефин комплексын эшләтеп җибәрү әһәмиятле бурыч булып тора.

Без «СИБУР» компаниясе җитәкчелегенә Казанда Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре үзәге ачу турында карар кабул итүе өчен рәхмәтле. Бу безнең предприятиеләребезгә базарда тоткан позицияләрен көчәйтү мөмкинлеге бирәчәк һәм Татарстанда химия һәм нефть химиясен киләчәктә үстерүгә яңа этәргеч бирәчәк.

«СИБУР»ның заманча хезмәт шартлары стандартларын кертүгә карашын аерым билгеләп китәргә телим. Бу максатларда 1 млрд сумнан артык акча тотылды. Шул исәптән көнкүреш биналары, медицина пунктлары һәм ашханәләр төзекләндерелде һәм яңача җиһазландырылды, «Бәхетле» компаниясе белән берлектә хезмәткәрләрне сыйфатлы ризык белән тукландыру оештырылды, автобуслар паркы яңартылды. «СИБУР» шулай ук Түбән Камада социаль объектларны яңартып коруда актив катнаша.

Һичшиксез, «Газпром» компаниясе безнең стратегик партнерыбыз булып тора. Татарстан – илдәге газ кулланучыларның иң эреләреннән берсе. «Газпром»га безнең башлангычларыбызга ярдәм күрсәтүе һәм гамәлгә ашырыла торган проектларны газ белән гарантияле тәэмин итүе өчен рәхмәт сүзләремне җиткерергә телим.

Бүгенге көндә республикада җитештерелә торган продукция күләменең якынча 60 проценты формалаштырыла торган нефть һәм газ тармагының әһәмиятен исәпкә алган хәлдә, геосәясәттә үзгәрешләр барган шартларда, Хөкүмәткә «Татнефтехиминвест-холдинг», предприятиеләребез белән берлектә 2025–2030 елларга тармакны үстерү буенча яңа программа эшләргә һәм кабул итәргә кирәк.

Татарстан – илнең машина төзү буенча эре үзәге. Тармакның әйдәүчесе – «КАМАЗ» автогиганты. Килеп туган четерекле шартларда завод илдә ихтыяҗ булган автотехниканы җитештерә, К5 мо-

Олег МОРОЗОВ,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:
– Мин – Юлламаларны элек тә тыңлаган кеше, монысын бик өлгергән, житешкән дип бәяләр идем. Игътибар иткән булсагыз, саннар аз иде. Татарстанның социаль-икътисадый стратегиясенә игътибар биреле. Иҗтимагый тормышның барлык өлкәләре дә телгә алынды, «Фәнни-технологик үсеш елы» игълан ителде. Татарстан бу җәһәттә дә алдынгы. Яңа вазгыятьтә, яңа шартларда сәнәгать җитештерүе, икътисад яңарыш кичерә. Юллама халыкка да якын булды. Туры трансляция оештырылды, барысы да күрде, тыңлады. Халык белән хакимиятнең аралашуы бу. Хәзер хакимият белән халыкның бергә булуы бик мөһим. Бурычлар күп, алар барысы да масштаблы.

Тимур СӨЛӘЙМАНОВ, Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте» илкүләм балалар һәм яшүсмерләр хәрәкәтенең Татарстан бүлеге җитәкчесе:
– «Алдынгылар хәрәкәте» турында мөһим сүзләр әйтелде. Яшьләрне гаилә кыйммәтләре нигезендә тәрбияләү турында сүз булды, сәләтле яшьләр белән эшләү мәсьәләсенә урын бирелде. Бер сәгатьтән артык барган Юлламада яшьләр сәясәтенә дә игътибар булды. Димәк, канатланып, эшебезне алга таба да дәвам итәчәкбез.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Дәүләт Советы депутаты:
– Быелгы Юллама яңалыгы белән аерылып тора. Рәиснең сүзе гамәленнән аерылмый. Ул татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында аерым әйтте. Аның хәзерге катлаулы вазгыятьтәге ролен атады. Гомумән, Юлламада бернәрсә дә читтә калмады. Иҗтимагый тормыш тулысынча колачланды. Уңышлар да күп, проблемалар да бар. Иң мөһиме – узган эшкә – салават дип, йомгак ясап, киләчәккә дөрес юллар эзләү.

Эльмира ЗАРИПОВА, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры:
– Юлламада тормыш сыйфатына бәйле барлык сораулар, көн кадагында торган махсус хәрби операция катнашучыларын яклау кебек мәсьәләләр телгә алынды. Төп игътибарыбыз социаль сәясәткә юнәлгән. Республикада гамәлдә булган барлык программалар, әйтик, яңа мәктәпләр төзү, хастаханәләрне төзекләндерү – алар барысы да кешенең тормыш сыйфатын күтәрүне күздә тота. Шуңа күрә Татарстанны яшәү, эшләү урыны буларак сайлыйлар.

Ирада ӘЮПОВА,
Татарстанның мәдәният министры:
– Юлламаның башыннан алып азагына кадәр рухи нигезгә игътибар бирелде. Юлламаның идеологик рухта булуын билгеләп үтәсе килә. Эшебез дә әнә шул рухи платформага таянып корылырга тиеш. Гомумән, рухыбызга инвестицияләр җәлеп итәргә кирәк. Киләчәккә планнар зур, эшләргә дә эшләргә генә.

Зилә ВӘЛИЕВА,
Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе:
– Рөстәм Нургали улы да әйтте: максат – эзлекле рәвештә, бер туктамый алга бару. Залда шулкадәр хөрмәтле кешеләр җыелган иде. Шуңа да Рәиснең Юлламасында рәхмәт сүзләре дә булу табигый. Чөнки ул куя торган зур бурычларны үз урыннарында зур нәтиҗәләргә, уңышларга ирешкән кешеләр үти. Табиблар булсынмы, укытучылармы, үсеп килүче яшьләр, дисеңме. Алда әле хәл итәсе мәсьәләләр бик күп. Шуңа да барыбызга да берләшергә кирәк.

дель рәтендәге йөк машиналарын, яңа буын үзбушаткыч машиналарны кертеп, сыйфатын яхшыртып серияле җитештерү җайга салынды, автобуслар һәм электробуслар җитештерү күләме арта. Завод җиңел электромобильләр җитештерүне булдырырга ниятли. Пилотсыз «КАМАЗ» йөк машиналары тест режимында Мәскәү һәм Санкт-Петербург арасында М11 федераль трассасы буйлап йөк ташый башлады.

Чит ил партнерының китүенә карамастан, завод үзенең ярдәмче предприятиеләрендә комплектлау детальләрен җитештерүне һәм компетенцияләрне саклап калды: «КАМА ДИЗЕЛЬ» дизель двигательләре компонентларын туплау проектын гамәлгә ашыруны дәвам иттерә, «ЦФ КАМА» роботлаштырылган тизлекне күчерү тартмаларын җитештерүне үзләштерә.

Чит ил инвесторы киткәннән соң эшчеләрен саклап калган һәм коммерциячел йөк машиналарының яңа линейкасын чыгара башлаган «Соллерс» компаниясен аерып атыйсым килә.

Быелның июлендә Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Владимирович Мишустин катнашында «Алабуга» махсус икътисадый зонасында двигательләр җитештерелә торган завод ачылды.

А.М. Горький исемендәге завод хәрби продукция җитештерү белән бергә, гражданнар өчен күп төрле суднолар җитештерә. Быел елгаларда пассажирлар йөртүнең сыйфатын яхшырту өчен республика предприятиедән А-217 проектлы теплоход һәм ике яңа «Метеор» сатып алды.

Илебез Президенты указы нигезендә «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе Россия Федерациясенең «Хезмәттәге уңышлары өчен» мактау билгесенә лаек булды.

Казан авиация заводында җитештерү өлкәсен тирәнтен яңартып кору дәвам иттерелә. Без илебез җитәкчелегенә Ту-214 самолетларын серияле җитештерүне арттыру турында карар кабул итүе өчен бик рәхмәтле.

Казан вертолет заводында җитештерүне киңәйтү буенча 28 млрд сумлык киң колачлы проект гамәлгә ашырыла, 3 елга алдан заказлар исемлеге төзелгән, шул исәптән экспортка товар чыгару буенча да, «Ансат» вертолеты өчен чит ил компонентларын алыштыру эше төгәлләнде.

Шулай ук «ЕЛАЗ», «РИАТ», «РариТЭК», «Казан авыл хуҗалыгы машиналары» заводлары яңа машиналар һәм җиһазлар номенклатурасын арттыра, ICL һәм «ЭлектроОптима» компанияләре югары технологияле продукция җитештерүнең яңа юнәлешләрен үзләштерә, КМПО, «АЛНАС» һәм бик күп башка предприятиеләр сәнәгать җитештерүе күләмнәрен арттыра бара.

Бүгенге көндә республиканың көчәйтелгән режимда эшләүче хәрби-оборона комплексы предприятиеләре Хөкүмәтнең аерым игътибар үзәгендә. Һичшиксез, тиешле срокларда һәм тулы күләмдә дәүләтнең оборона заказын үтәү төп бурыч булып тора. Шулай ук тупланган хәрби тәҗрибәне исәпкә алып, чыгарыла торган продукцияне камилләштерү сорала.

Предприятиеләребезнең хезмәт коллективларына илнең икътисадын һәм оборона сәләтен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен рәхмәт сүзләремне җиткерәм.

Хәзерге шартларда предприятиеләрнең сәнәгать ягыннан һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлыгын тәэмин итү гаять зур әһәмияткә ия. Җитәкчеләргә бу эштә шәхсән җаваплылык йөкләнә. Хөкүмәткә федераль үзәк белән бергәләп предприятиеләрнең террорчылыктан сакланганлыгы буенча аерым дәүләт программасын формалаштыру мәсьәләләрен эшләүне йөклим.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү – икътисад үсешенең иң әһәмиятле факторларының берсе. Әлеге бурычны хәл итү, барлык төп компонентларны колачлаган төстә, системалы алып барылырга тиеш.

Эшне мәктәптән үк башларга кирәк. Соңгы елларда БДИ бирү өчен профильле математика, физика һәм химия кебек юнәлешләрне сайлаучы мәктәп укучылары санының кимүе кебек хәвефле күренеш күзәтелә. Әлеге хәлне үзгәртү зарур. Моның өчен һөнәр сайлауда дөрес юнәлеш бирергә, предприятиеләр катнашында юнәлеш сайлаганчы һәм юнәлеш сайлаганнан соң укыту эшен җайга салырга, балаларны иҗади, уйлап табу эшчәнлегенә җәлеп итәргә кирәк. Бу эштә һөнәр белән кызыксынуны арттыра торган чемпионатлар хәрәкәтенә һәм конкурс чаралары уздыруга аерым роль бирелә.

Белгечләр әзерләү тәгаен предприятиеләр ихтыяҗларын исәпкә алып барылырга тиеш. Бу максатларда республикада 47 ресурс үзәге эшли. Әлеге модель үзенең нәтиҗәле булуын раслады инде. Мисалга, Әлмәт политехника көллияте, Кукмара аграр һәм Казан авиация-техник көллиятләрен китерергә мөмкин.

Моннан тыш, «Алабуга Политех» эшче белгечләрне әзерләү үзәгендә, «ПОЗиС» заводы өчен белгечләр әзерләүче Зеленодольск механика көллиятендә җитештерүдә эшкә өйрәтү кластеры булдырылды, аларда укучыларның саны 3 елдан 10 меңгә җитәргә тиеш.

Суднолар төзү тармагын кадрлар белән тәэмин итү максатларында Зеленодольск суднолар төзү көллияте ачылды.

Чаллының ресурс үзәкләре белән «КАМАЗ» компаниясе актив эшчәнлек алып бара.

Алдынгы инженерлык мәктәпләрен ачу киләчәгә өметле проект булып тора. Машина төзелеше, нефть химиясе, ИТ-өлкәдә һәм биотехнологияләр өлкәсендә 4 мәктәп үз эшчәнлеген башлады инде.

Моннан тыш, республика Хөкүмәтенә Фәннәр академиясе, предприятиеләр, Югары уку йортлары ректорлары шурасы белән бергәләп авиация һәм вертолетлар төзү, төзелеш, авыл хуҗалыгы, медицина технологияләре өлкәләрендә компетенцияләр үзәкләрен булдыру эшен дәвам иттерергә кирәк.

Югары уку йортларыбыз алдында югары уку йортлары даирәсендә технологик эшкуарлыкны үстерү, дөнья дәрәҗәсендәге фәнни-мәгърифәти үзәкләр төзү буенча федераль проект, шулай ук «Приоритет – 2030» стратегик лидерлык федераль программасы кысаларында эшне активлаштыру бурычы тора.

Тулаем алганда, төп өстенлекләр һәм киләчәк эш юнәлешләре республиканың кабул ителгән Фәнни-технологик үсеше программасында чагылыш таба. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе аны гамәлгә ашыруга идарә итүне берләштерүче үзәк булып торырга тиеш. Хөкүмәтебезгә әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең вәкаләтләрен ныгыту һәм аның ресурслар белән тәэмин ителешен көчәйтү буенча тиешле тәкъдимнәр кертү зарур.

Фәннең һәм инновацияләрнең алдында торган бурычларны хәл итүдә мөһим ролен аңлап, Россия Федерациясендә Фән һәм технологияләр унъеллыгы, Россия фәненең 300 еллыгы кысаларында киләсе елны Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итәм.

Галимнәребезнең эшләнмәләре лабораторияләр чикләрендә генә калырга тиеш түгел. Аларның нигезендә яңа җитештерүләр булдырырга кирәк. Моның өчен республикада бизнеска ярдәм итү инфраструктурасы, шул исәптән «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналары, «Химград» технополисы, «КИП Мастер», ИТ-парклар эшләп килә.

Бизнесны үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру – безнең алда торган иң өстенлекле бурычларның берсе. Киләчәктә әлеге юнәлештә эшне дәвам итү өчен безнең мөмкинлекләребез бар. Беренче чиратта, бу инвестиция проектларын гамәлгә ашыру белән бәйле процедураларны узу вакытын һәм документлар санын киметүгә кагыла. Әлеге эш «Росатом» дәүләт корпорациясе ярдәме белән «Югары тизлектәге инвестиция агымы» проекты кысаларында алып барыла, юл карталары эшләнде. Тармак министрлыклары һәм ведомстволар, ресурслар белән тәэмин итү оешмалары, муниципалитетлар Икътисад министрлыгы җитәкчелегендә аларның билгеләнгән срокларда үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

Тагын бер кат искәртеп китәм: эшкуарлар һәрвакытта да халыкның иң актив һәм эшлекле өлеше булды һәм шулай булып кала да. Киң колачлы үзгәрешләр чорында алар булдыклы һәм нык холыклы буларын тагын бер кат раслап, эш урыннарын саклап калуга ирешә һәм яңа эш урыннары булдырды, заман таләпләренә туры килә торган яңа продукция җитештерә башлады, республикадан читтә дә танылган үз брендларын үстерүне дәвам итте.

Кече һәм урта бизнес – икътисад төзелешен үзгәртеп коруда төп корал.

Эшкуарлык мохитен яхшырту, аерым алганда, яңа кече һәм урта предприятиеләр субъектлары булдыруга кызыксынганлык тудыру, бизнесның югары сыйфатлы үсешен, аның икътисадның киләсе баскычына – вак компанияләрдән кече компанияләргә, кече компанияләрдән урта компанияләргә күчешен тәэмин итү, икътисадның реаль секторы – җитештерүчеләребезнең бизнесын үстерү, шулай ук эшкуарларга чит ил базарларына чыгуга ярдәм итү һәм үз сәүдә маркаларын танытуга комачаулаучы чикләүләрне бетерү безнең өчен өстенлекле бурыч булып тора.

Моннан тыш, сәнәгать паркларының, цифрлы нигезгә корылган сервисларның, шул исәптән Республика маркетинг үзәге, МСП.РФ федераль цифрлы платформаның, шулай ук интернет-сәүдә мәйданчыкларының мөмкинлекләреннән активрак файдаланырга кирәк.

Монда эшлекле даирә белән кара-каршы элемтә урнаштыру мөһим. Бизнес-берләшмәләрдән җитди тәкъдимнәр көтеп калабыз. Республика Хөкүмәтенә тиешле чаралар планы әзерләүне йөклим.

Хөрмәтле депутатлар!

Икътисадның төп тармакларыннан берсе – авыл хуҗалыгы.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен, корылык булу сәбәпле, бу ел җиңел булмады. Ләкин шулай да игенчеләребез бөртеклеләрдән 3,7 млн тонна уңыш җыеп алуга иреште. Шулай ук 1,5 млн тоннадан артык шикәр чөгендере, кимендә 800 мең тонна бәрәңге һәм 300 мең тонна яшелчә җыеп алыныр дип көтелә. Бу исә республикабыз халкын тулысынча азык-төлек белән тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк.

Авыл хезмәтчәннәренә катлаулы, әмма гаять әһәмиятле хезмәтләре өчен олы рәхмәтемне белдерәм!

Әлеге күрсәткечләр – авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән минераль ашламалар сатып алуга субсидияләр бирү, мелиорациягә булышлык итү, сугару җирләрен булдыру, дым саклау технологияләрен куллануга кертү, техник яңарту программаларын гамәлгә ашыру буенча соңгы елларда алып барылган планлы эшнең нәтиҗәсе булып тора.

Без авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен һәр елны ташламалы бәядән дизель ягулыгы белән тәэмин итүче «Татнефть» компаниясенә рәхмәтлебез.

Кайбер хуҗалыклар, табигать шартларының уңай булмавына да карамастан, быел актив рәвештә яңа технологияләрне кулланышка кертә барып, яхшы уңыш алуга иреште. Алар – «КОЛОС», «Нармонка», «Актаныш» компанияләре, шулай ук фермерлар – Илгиз Заһиев, Зөфәр Мөхәммәтшин, Азат Дәүләтшин, Равил Бикчуров.

Татарстан – илдә сөт җитештерү буенча алдынгылар сафында. Биредә иң мөһиме – эш тизлеген киметмәү. Узган елда беренче тапкыр без 2 млн тоннадан артык сөт җитештердек. Тәүлегенә 400 тоннадан артык сөт җитештерелә торган Кукмара районының, көн саен 300 тоннадан артык сөт җитештерә торган Саба, Әтнә һәм Балтач районнарының өлеше аеруча зур.

Алдынгы хуҗалыкларны аерым билгеләп үтәсем килә. Алар – Мамадыш районының «Авыл хуҗалыгы комплексының азык-төлек программасы», Тукай районының «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе», шулай ук «Август-Агро» компаниясе. Хуҗалык җитәкчеләрен һәм фермерларыбызны бүген бирегә чакырдык. Бик зур рәхмәт сезгә!

Республикада терлекчелекне үстерү өчен нәселле терлек сатып алудан башлап югары технологияле комплекслар һәм терлек азыклары үзәкләре төзүгә кадәр, барлык юнәлешләрдә ярдәм күрсәтелә.

Әлеге ярдәм чаралары һәркемгә бертигез күләмдә бирелә, әмма төрлечә файдаланыла. Мәсәлән, узган елда Чүпрәле һәм Кама Тамагы районнарында нәселле терлек бөтенләй сатып алынмаган, бүгенге көндә Чүпрәле, Зеленодольск, Югары Ослан, Балык Бистәсе, Менделеевск, Әлмәт, Лаеш һәм Питрәч районнарында бер генә эре инвестиция проекты да тормышка ашырылмый.

Нәтиҗәдә бары тик бер Кукмара районында гына әлеге 8 район бергә җитештергәннән артыграк сөт җитештерелә. Бу – елына 140 мең тонна сөт.

Төп бурыч – терлекләрнең баш саны кимүгә юл куймау. Безнең агрохолдинглар тарафыннан терлекләрнең баш санын торгызу, яңа терлекчелек комплекслары төзү буенча юл карталары кабул ителде. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының бурычы – аларның үтәлешенә контрольне тәэмин итү.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

ИТ-өлкәне үстерү мөһим юнәлеш булып тора.

319 дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең барысы да электрон рәвештә күрсәтелә башлады. Быел татарстанлыларга электрон портал аша 2 миллионга якын хезмәт күрсәтелде. Моннан тыш, гражданнарга тагын күпфункцияле үзәкләр аша 3 млн хезмәт күрсәтелде. Республикада аларның саны 60ка җитте.

Безнең бурыч – халыкка хезмәт күрсәтүне мөмкин булганча гадиләштерү. Моның өчен, мәсәлән, бала тууны яисә никахны теркәү кебек төрле тормыш хәлләренә мөнәсәбәтле рәвештә алдан чарасын күреп эш итүгә нигезләнгән хезмәтләр күрсәтүне үстерү һәм куллануга кертү мөһим. Шулай ук хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты начараюга юл куймау һәм срокларны үтәү гаять әһәмиятле.

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә электрон хезмәт күрсәтү – «Локоло» сервисы көннән-көн популярлаша бара. Республикада күпфатирлы йортларда яшәүче 4 меңнән артык кеше аннан файдалана инде. Әлеге сервисны үстерүдә киләсе адым булып аңа бакчачылык ширкәтләрен кушу мөмкинлеге тора.

Мәгариф өлкәсендә шәһәр һәм авыл мәктәпләренең заманча мәгариф ресурсларыннан бердәй файдалана алуын тәэмин итү өчен ел ахырына республикада коллегаларыбыз – Мәскәү электрон мәктәбе базасы нигезендә яңа сервислар гамәлгә кертеләчәк. Моннан тыш, без укытучыларыбызны ноутбуклар белән тәэмин итү эшен дәвам итәрбез. «АК БАРС» банкка аеруча зур рәхмәт әйтәсем килә, аның ярдәме белән ике ел эчендә укытучыларга 36 мең ноутбук бирелде.

Республикада сәламәтлек саклау өлкәсендә дөньякүләм стандартлар буенча бердәм электрон контур булдырыла. Ул белгечләргә аз вакыт эчендә һәм төгәл диагноз куюда ярдәм итәчәк ясалма интеллект белән җиһазландырылачак, шулай ук медицина учреждениеләрендә көн дә кабатлана торган эшләрне автоматлаштыру мөмкинлеге бирәчәк. Ел ахырына кадәр Түбән Кама район хастаханәсе базасында әлеге системаны сынау эшләрен төгәлләү зарур. Медицина хезмәтенең сыйфатын яхшырту өчен өстәмә рәвештә ашыгыч медицина ярдәме хезмәтен дә автоматлаштыру таләп ителә.

Һәр елны сәнәгать предприятиеләренең цифрлы үсешен бәяләү уздырыла. Биредә, гадәттәгечә, КАМАЗ, «Татнефть», «Татэнерго» оешмалары алдынгылыкны бирми. Ләкин цифрлы технологияләрне җитәрлек дәрәҗәдә кулланмаучы компанияләр дә бар. Тагын бер кат җитәкчеләрнең игътибарын шуңа юнәлтәсем килә: цифрлаштыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда һәм конкурентлыкны үстерүдә мөһим фактор булып тора.

Мәгълүмат куркынычсызлыгын, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системаларының куркынычсызлыгын тәэмин итү – бик әһәмиятле мәсьәлә. Интернет челтәрендә кулланучыларның төрле куркынычларга юлыгу очраклары узган ел белән чагыштырганда 7,5 тапкырга артты. Җаваплы ведомстволарга куркынычсызлыкны тәэмин итү, бизнеска һәм халыкка саклык чаралары турында мәгълүмат бирү буенча эшне тиешле дәрәҗәдә уздыруны тәэмин итәргә кирәк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Безнең эшебезнең төп нигезе – халыкның тормыш сыйфатын яхшырту. Әлеге максат белән Татарстанда илкүләм проектлар һәм республика программалары кысаларында киң колачлы планлы эш алып барыла. Бары тик быел гына да 114 млрд сумга 4070 социаль-мәдәни өлкә объекты төзеләчәк, үзгәртеп корылачак һәм төзекләндереләчәк. Бу – яңа мәктәпләр, балалар бакчалары, яшьләр үзәкләре, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт объектлары.

Моннан тыш, ел ахырына кадәр тулаем республика буенча 725 күпфатирлы йортта капиталь төзекләндерү эшләре тәмамланачак.

«Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә бик күп уңай фикерләр ишетәбез, ел саен меңгә якын ишегалды тәртипкә кителә, шулай ук җәмәгать урыннарын төзекләндерү эшләре башкарыла. Быел бөтен республика буенча 68 объектта эшләр тәмамланачак.

Без шулай ук республика башкаласы өчен гаять әһәмиятле проектларны тормышка ашыру эшен башладык. Казансу елгасы ярында Милли китапханә белән янәшә балалар паркы ачу, шулай ук Галиәсгар Камал театрының яңа бинасын төзү күздә тотыла, ул Кабан күле һәм Иске Татар бистәсе экосистемасын берләштерәчәк, күренекле архитектура объекты һәм татар мәдәнияте үзәге булачак.

Киров дамбасы янындагы территория шулай ук республика халкын һәм аның кунакларын үзенә тартып тора торган тагын бер урын булачак. Биредә су өстендә ял итү өчен шартлар булдырылган яңа җәмәгать урыны барлыкка киләчәк.

Шәһәрләрне үстерү институтына, Иҗтимагый киңлекләрне планлаштыру институтына Казан мэриясе белән берлектә тиешле мастер-план эшләүгә керешергә кирәк.

Тулаем алганда, башкарылган әлеге эшләр туристларның республикага тагын да күбрәк килүен тәэмин итүгә ярдәм итәчәк. Быел аларның саны 4 млн кешедән артачак.

«Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проектының ярдәм чараларыннан, аерым алганда, бөтен республика буенча туристлык инфраструктурасын үстерү, шәһәрдән читтә урнашкан ял итү объектлары – глэмпинглар, автокемпинглар, заманча ял базалары,

Игорь ТУЛЬЧАНСКИЙ, хәрби династия вәкиле:

– Шулай чакыруларына, басып алкышлауларына күңел булды, әлбәттә. Республикабыз өчен гаять мөһим чара бит бу. Рәхәт булды. Күп яңалыклар белдек, Рәисебезне ишеттек. Татарстанда гаять зур чаралар көтелә икән. Кыскасы, балаларга, оныкларга сөйләрлек көн булды бу! Әтиебезгә 88 яшь тулачак. Бу көнне көтте, чын хәрби кеше буларак, әзерләнеп торырга фәрман булуга, матур киемнәрен әзерләде.

Ринат ФАЗЫЛОВ, «Халык фронты» илкүләм иҗтимагый хәрәкәте төбәк бүлекчәсенең башкарма комитеты җитәкчесе:

– Юлламада махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм мәсьәләләренә зур урын бирелде. Рөстәм Миңнеханов батыр егетләребез алдынгы сафта торганда бернигә дә мохтаҗ булмасын, якыннары өчен җаны тыныч булсын өчен барлык шартлар тудырылырга тиешлеген искәртте. Республиканың махсус операциядә катнашкан якташларыбызга зур гуманитар ярдәм күрсәтүен дә билгеләп үтте. Рөстәм Миңнеханов үз Юлламасында яшьләр турында да үтемле сүзләр әйтте. Без киләчәккә зур планнар корабыз. Теләсә кайсы дәүләтнең нигезен яшьләр тәшкил итә.

Тимирхан АЛИШЕВ, КФУның тышкы элемтәләр буенча проректоры:

– Татарстан Рәисе үз Юлламасында Россиянең изоляциясе турындагы уйдырмаларга да тукталды. Бу сүзләр дәреслеккә туры килми, билгеле. Безгә чит илләрдән ничаклы студент – укырга, күпме кеше эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырга килә. Икътисад тармагында күпме бәйләнешләребез бар. Вазгыятьнең чынлыкта нинди булуына инану өчен әнә шуларны искә төшерү дә җитә. Рөстәм Миңнеханов киләсе елда узачак БРИКС саммиты турында да сөйләде. Дөрестән дә, Россиянең, Татарстанның халыкара процессларда актив катнашканын тагын бер кат раслау өчен менә дигән мөмкинлек бу.

Марат БАРИЕВ, Россия Олимпия комитетының башкарма комитеты әгъзасы:

– Бүгенге Юллама ил-көндәге вазгыятькә туры килә. Татарстан Рәисенең шул вазгыятькә, проблемаларга карашы, бәясе халык өчен дә бик мөһим. Рөстәм Миңнехановның патриотик һәм хезмәт тәрбиясе, яшьләр проблемалары турындагы фикерләре аеруча игътибарга лаек. Гомумән алганда, Юлламада ике мөһим бурыч куелды. Беренчедән, халыкның тормыш сыйфатын күтәрү. Моңа мәгариф тә, сәламәтлек саклау өлкәсе дә, мәдәният тә – барысы да керә. Икенчесе – территорияләрне комплекслы рәвештә үстерү. Ягъни яңа территорияләр уйланып төзелергә, аларда халык өчен барлык уңайлыклар да булырга тиеш.

Рафаэль ШАКИРҖАНОВ, «Боевое братство» Бөтенроссия оешмасының Татарстан бүлеге советы рәисе:

– Татарстан Рәисе Юлламасын патриотик тәрбия темасыннан башлавы бик дөрес һәм урынлы булды. Моннан тыш, залда махсус хәрби операциядә катнашучыларның булуы да зур әһәмияткә ия. Рөстәм Миңнеханов Җиңү паркында махсус хәрби операциягә багышланган мемориаль комплекс ачылачагын да хәбәр итте. Мондый һәйкәлләр балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә бик мөһим рольләрнең берсен уйный.

шулай ук республиканың туристлык үзәкләрендә яңа кунакханәләр төзү өчен инвестиция мәйданчыклары булдыру өлешендә мөмкин булганча күбрәк файдаланырга кирәк.

Яңа туристлык территориясе төзү буенча «Лаеш» проекты федераль дәрәҗәдә хупланды. Кама елгасы яр буенда ел әйләнәсендә эшли торган курорт барлыкка киләчәк.

Татарстанда тормышка ашырыла торган илкүләм проектлар һәм дәүләт программалары халыкның тормыш сыйфатын яхшыртып кына калмыйча, муниципаль берәмлекләрне үстерүгә көчле этәргеч бирә, республикабызны тагын да үстерүгә, уңай якка үзгәртүгә хезмәт итә.

Илкүләм проектларны һәм республика программаларын гамәлгә ашыруның кешеләр өчен никадәр мөһим булуын без яхшы аңлыйбыз. Шуңа күрә тизлекне киметмәү – безнең төп бурычыбыз.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Гамәлгә ашырыла торган программаларның һәм проектларның нәтиҗәлелеген арттыруда иң мөһиме – аларның территорияләрне комплекслы үстерү максатларында бер үк вакытта гамәлдә булуын тәэмин итү.

Беренче чиратта, бу торак, транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктура төзүгә карый. Бирегә төп роль Иҗтимагый киңлекләрне планлаштыру институтына бирелә.

Владимир Владимирович Путин башлангычы белән федераль дәрәҗәдә инфраструктура проектлары тормышка ашырыла, алар Идел буе төбәкләрен, Үзәк Россия һәм Уралны тоташтырачак яңа логистик маршрутлар төзүгә, шулай ук төбәкләр арасында берләшүне көчәйтүгә өстәмә этәргеч бирәчәк.

Быел декабрь ахырында М12 трассасы һәм Идел аша өч километр озынлыгындагы яңа күпер буенча хәрәкәт ачылачак, ул Казан шәһәрен көньяктан урап үтү мөмкинлеге бирәчәк. Барлык юллар да беренче категорияле булачак. Казаннан Мәскәүгә бары 6,5 сәгатьтә барып җитү мөмкин булачак.

Шулай ук Кама елгасы аша салынган күперле, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап уза торган М7 трассасы төзелә, киләчәктә әлеге юл реконструкцияләнеп, Чаллыдан Башкортстан чикләренә кадәр узачак. Бу Кама агломерациясенең транспорт инфраструктурасына артык йөкләнешне киметергә ярдәм итәчәк. Бу – бик зур һәм кирәкле проект. Аны тормышка ашыруда ярдәме өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Шакирҗан улы Хәснуллинга олы рәхмәтебезне белдерәбез.

Казан – Оренбург федераль трассасына тоташачак Алексеевск – Әлмәт юлын төзүне тәмамлау 2024 елга бурыч булып тора. Киләсе этап – Әлмәт – Баулы участогында юл төзелешен дәвам итү. Проектны гамәлгә ашыру Казан һәм Әлмәт агломерацияләре арасында югары тизлектә хәрәкәт итү мөмкинлеге бирәчәк.

Стратегик бурычыбыз – М7 һәм М5 федераль трассаларын беренче категория юллар белән бергә тоташтыру.

Моннан тыш, республикабыз башкаласында Горький шоссесын үзгәртеп кору эшләре дәвам иттерелә, аңа алмаш булган беренче участок төзелеп бетте, быел Әмәт магистраленнән Җиңү проспектына кадәр Вознесение трактының беренче этабы кулланугa тапшырылачак.

Без әлеге проектларны тормышка ашыруда ярдәме өчен Россия Хөкүмәтенә зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Болар белән бергә Татарстанда төбәк әһәмиятенә ия булган юлларга да зур игътибар бирелә. Без һәр елны авылларда кимендә 700 километр озынлыкта юлларны төзибез һәм төзекләндерәбез. Әлеге эшне дәвам иттерәчәкбез.

Җәмәгать транспортын үстерү – тагын бер мөһим юнәлеш. Илебез җитәкчелеге ярдәме белән хәрәкәт составын яңарту мөмкинлеге барлыкка килде. Якын арада Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зеленодольск, Алабуга, Бөгелмә, Лениногорск, Зәй, Азнакай, Минзәлә, Нурлат һәм Баулы шәһәр һәм шәһәр яны маршрутлары өчен уңайлыклары булган 400дән артык заманча автобус сатып алыначак. Транспорт министрлыгына муниципалитетлар белән берлектә аларны маршрутларда нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә кирәк. Бу автобус паркының дүрттән бер өлешен яңарту мөмкинлеге бирәчәк.

Быел Габдулла Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында 5 миллионнан артык пассажирга хезмәт күрсәтелде. Яңа терминал төзү турында карар кабул ителде. Инде киләсе елда ук эшне башларга кирәк булачак.

Николай Лемаев исемендәге «Бигеш» халыкара аэропортының яңа терминалын төзүдә ярдәме өчен КАМАЗга һәм шәхсән Сергей Анатольевичка зур рәхмәтемне белдерәм. Хөкүмәткә Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы белән берлектә самолетлар өчен очып китү-төшү полосасын үзгәртеп кору мәсьәләсен эшләү зарур.

«Татнефть» компаниясе ярдәме белән бүгенге көндә «ЮВТ-АЭРО» авиакомпаниясе 40 маршрут буенча Татарстан аэропортларыннан очышлар ясый. Якын арада паркка Казан авиация заводында җитештерелгән дүрт Ту-214 самолеты алуны планлаштырабыз.

Шулай ук үзебезнең туристлык үзәкләренә кадәр һәм «Бөек Идел юлы» проекты кысаларында елга маршрутлары челтәрен дә үстерү зарур. 2025 елга республикада елга транспортында йөрүче пассажирлар санын елына 500 мең кешегә җиткерү бурычы тора. Әлеге эштә бу елны оештырылган «Татарстан Республикасы флоты» судно компаниясе төп таяныч булачак.

Республикада киләчәктә йөк ташу юнәлешендә транспорт-логистика челтәрен үстерү өчен Хөкүмәтебезгә, йөкләрне контейнерларда эшкәртүгә төп игътибарны юнәлтеп, шулай ук «Көнчыгыш – Көнбатыш» һәм «Төньяк – Көньяк» халыкара транспорт коридорларында йөк ташуны тәэмин итү өчен бердәм цифрлы транспорт-логистика мохите булган мультимодаль төенләнеш үзәкләренең төп челтәрләрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне йөклим.

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә инженерлык челтәрләренең тузган булуы борчулы мәсьәлә булып кала. Бүгенге көндә аларның 30 проценттан артыгын алмаштыру таләп ителә. Безнең бурыч – коммуналь инфраструктура системаларын яңарту буенча илебез Президенты йөкләмәсе нигезендә гамәлгә куелган федераль программаның нәтиҗәле үтәлүен тәэмин итү. Хөкүмәтебезгә федераль финанслау күләмен республика өчен саклап калу мәсьәләсен карап тикшерүне йөклим.

Торак фондына идарә өлкәсе шулай ук төп игътибар үзәгендә булырга тиеш. Элеккечә үк идарәче компанияләргә, аларның техник тәэминатына һәм кадрлар составына кагылышлы сораулларыбыз бар әле. Муниципалитетларга, Дәүләт торак инспекциясенә аларның эшен катгый рәвештә контрольдә тотуны йөклим. Тәзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь министрлыгына федераль үзәк белән берлектә идарәче компанияләргә лицензияләр бирү таләпләрен тагын да кырысландыруга кагылышлы законнар эшләү мәсьәләсен карап тикшерүне йөклим.

Йорт эчендәге, фатир эчендәге газ җиһазларына һәм җылләтү системаларына хезмәт күрсәтүнең куркынычсызлыгын арттыру шулай ук көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала. Кызганычка каршы, безнең барлык башлангычларыбыз да әлегә федераль дәрәҗәдә хуплау тапмады. Республика Хөкүмәтенә әлеге мәсьәләне хәл итү өчен федераль коллегалар белән эшне дәвам итү зарур.

Моннан тыш, муниципаль берәмлекләр башлыклары кичектергесез рәвештә Дәүләт торак инспекциясе белән берлектә газ җиһазларына хезмәт күрсәтүне тиешле контрольдә тотуны һәм халык белән аңлату эшләре алып баруны тәэмин итәргә тиеш.

Хөрмәтле депутатлар!

Белем һәм тәрбия бирү системасын өзлексез рәвештә камилләштерү – һәр илнең уңышлы киләчәге, технологик үсеш ягыннан алдынгылыгы нигезе.

Матди-техник базаны яхшырту белән берлектә, тармак программаларын тормышка ашыруга һәм кадрлар әзерләүгә зур акчалар бүлеп бирелә. Шуның белән берлектә, бертигез мөмкинлекләр бирелүгә дә карамастан, без дәүләт аттестациясе узучыларның нәтиҗәләре төрле булуын күрәбез. Тукай, Ютазы, Лаеш, Буа һәм Менделеевск районнарында БДИ нәтиҗәләре, тулаем республика буенча алганда, уртачадан түбәнрәк.

Моннан тыш, быел имтиханнарын 100 баллга тапшырган бер генә укучы да булмаган, шулай ук мәктәпне тәмамлау турында аттестат бирелмәгән укучылар булган районнар да бар. Бу – Тукай һәм Ютазы районнары.

Мондый хәл булырга тиеш түгел. Мәгариф һәм фән министрлыгына муниципалитетлар белән берлектә муниципаль мәгариф органнарының эш системасын тикшерергә, педагогика өлкәсендәге стандартларга туры килүне тәэмин итүче технологияләрне һәм методик алымнарны камилләштерергә кирәк.

Илебездә игълан ителгән Укытучы һәм остаз елында республиканың барлык педагогика өлкәсе хезмәткәрләренә кагылышлы зур эш алып барыла. Бу укытучыларның югары абруен һәм аларның хезмәтенең әһәмиятен тагын бер кат дәлилли.

Әлеге һөнәр ияләренә хөрмәт йөзеннән без Казанда Укытучы скверы ачу турында карар кабул иттек.

Яраткан тәрбиячесе, укытучысы яки тренеры һәр кешенең тормышында зур роль уйный. Алар һәркемнең, аеруча баланың тормышында зур әһәмияткә ия. Үз эшенә күңел җылысын, йөрәк назын салып, алар булачак шәхес тәрбияли. Бүген без шушы залга гомерләрен яраткан һөнәренә багышлаган укытучыларны һәм остазларны чакырдык. Укытучылар Рәмзия Мидхәт кызы Шәрәпова, эш стажы – 48 ел һәм Тамара Михайловна Вәлишина, стажы – 49 ел; балалар бакчасында 43 ел тәрбияче булып эшләгән Лидия Ивановна Шулаева, үзенең гомерен куркыныч астына куеп, янгыннан ике кешене коткарган балалар тренеры – Хәмзә Мөхәммәтбәшир улы Юнысов, эш стажы – 39 ел.

Сезгә һәм барлык укытучыларга һәм остазларга хезмәтләре өчен олы рәхмәтемне белдерәм!

Милли мәгариф системасы һәрчак безнең игътибар үзәгендә. Туган телләрне өйрәнү һәм туган телләрдә укыту өчен шартлар бар, кадрлар әзерләү буенча эш алып барыла.

«Адымнар» мәктәпләре челтәре уңышлы эшли. Алар – милли мәгарифнең ресурс методик үзәге. Минтимер Шәрип улы, Сезгә бу идеяне тәкъдим итүегез һәм әлеге теманы үстерүдә шәхси катнашуыгыз өчен бик зур рәхмәт.

Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия тел мохитен саклауга зур өлеш кертә. Хакимият органнары, иҗтимагый оешмалар белән 100гә якын уртак проект булдырылды. Әлеге чаралар татар телен генә түгел, республикада яшәүче башка милләт телләрен – рус, чуаш, удмурт, мари, мордва телен үз эченә ала. Бу эш милли мәгариф һәм мәдәният өлкәсе өчен олы әһәмияткә ия. Аны әйдәп бару өчен Марат Готыйф улы Әхмәтовка рәхмәтемне белдерәм.

Туган телләрне сыйфатлы итеп өйрәнүне балалар бакчасыннан алып югары уку йортларына кадәр тәэмин итәргә кирәк.

Гомумән, тел мохитен формалаштыру – муниципаль һәм дәүләт хакимияте органнарының төп бурычының берсе. Моннан тыш, ике дәүләт телен куллану өчен барлык шартларны да булдыру мөһим.

Яшьләргә үз-үзен таныту, үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен республикада барлык шартларның да тудырылган булуы – безнең бик зур өстенлегебез. Әлеге максатларда Татарстанда заманча яшьләр инфраструктурасын үстерү буенча эш алып барыла, яшьләрнең иҗтимагый оешмаларына һәм аларның башлангычларына ярдәм күрсәтелә, адреслы грантлар бүлеп бирелә.

Республикабызда бик күп сәләтле яшьләребез бар, без аларның уңышлары белән бик горурланабыз. Бүген без залга республиканың сәләтле яшьләрен чакырдык. Алар – фән һәм инновация өлкәсендә Россия Президенты премиясе лауреаты Ирек Мөхәммәтдинов, халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр: Никита Перов (химия буенча), Максим Большаков (математика буенча), Валерий Родионов һәм Гыйймран Абдуллин (информатика буенча), Лекторларның мәктәп лигасында җиңүче Илья Садрисламов, Татарстанның ел укучысы Роман Моисеев, махсус хәрби операциядә катнашучылар турында китап авторы Әмир Вәлиуллов, «Архипелаг 2023»тә дроннар ярышларында җиңүче Булат Нургалиев. Сезгә киләчәктә дә зур уңышлар телим!

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Кешенең иң зур байлыгы – сәламәтлек. Аны саклау бурычын без чын профессионалларга гына ышанып тапшыра алабыз. Табиб – зур фидакарьлек таләп итүче һөнәрләрнең берсе. Медицина хезмәткәренең бер җылы сүзе, бер елмаюы да дәвалау сәләтенә ия. Татарстанның медицина учреждениеләре коллективларына көндәлек тырыш хезмәтләре, һөнәри осталыклары, үз эшен яратып башкарулары өчен олы рәхмәтемне белдерәм.

Республикада медицина хезмәте күрсәтү системасын яңарту, югары медицина технологияләрен, шул исәптән органнарны күчереп утыртуны актив куллану, аналарны һәм балаларны саклау, туучылар санын һәм гомер озынлыгын арттыру буенча зур эш алып барыла. Бу елда гына да яңа 60 объект, шул исәптән Казан шәһәренең 6 номерлы балалар поликлиникасы, Зеленодольск районы Осиново бистәсендә күпфункцияле поликлиника ачылды, Казан шәһәренең 7 номерлы клиник хастаханәсенең Перинаталь үзәгендә төзелеш эшләре тәмамланып килә.

Башлангыч медицина ярдәме күрсәтү пунктлары сәламәтлек саклау системасының әһәмиятле буыны булып тора. Биредә кадрлар җитмәү мәсьәләсе элеккечә үк актуаль булуын билгеләп үтәсем килә. Бу исә булган персоналга өстәмә эш йөкләүгә китерә, ә бу, үз чиратында, медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый. Әлеге мәсьәлә Зеленодольск, Түбән Кама һәм Бөгелмә районнарында аеруча кискен тора. Республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгына район башлыклары белән берлектә әлеге мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр бирүегезне сорыйм.

Халык сәламәтлеген саклауда төп роль диспансеризация уздыруга бирелә. Быел безнең сәнәгать предприятиеләре дә әлеге эштә актив катнаша. 80 мең хезмәткәр тикшерү узды. Җитәкчеләренең хезмәткәрләре сәламәтлегенә игътибарлы мөнәсәбәттә булуына мисал буларак «Татнефть», «СИБУР», «КАМАЗ», «ПОЗиС», «Зеленодольск суднолар төзү заводы» оешмаларын күрсәтергә мөмкин.

Халыкка диспансеризация уздыру эшен киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк. Хатын-кызлар һәм бала табарга карар кылган гаиләләр, шулай ук ерак авылларда яшәүчеләр аерым игътибар таләп итә.

Бу юнәлештә 5 мобиль медицина комплексы гаять нәтиҗәле эшләп килә. Шушындый тикшеренүләр нәтиҗәсендә бу елда гына да 3 меңгә якын кешенең авырулары ачыкланып, аларга үз вакытында медицина хезмәте күрсәтелде. Медицина тикшеренүләренең сыйфатын яхшырту өчен комплексларны флюорограф, маммограф кебек өстәмә җиһазлар белән тәэмин итү планлаштырыла.

Сәламәтлекне ныгытуда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү төп рольне уйный. Бездә моның өчен бөтен шартлар да бар. Универсиададан мирас булып калган объектлар спорт инфраструктурасын һәм тулаем спортны үстерү өчен яхшы нигез булып тора.

Бүген Татарстан – илебездә спорт объектлары саны буенча алдынгылар сафында. Ләкин шулай да, республиканың кайбер районнарында, спорт инфраструктурасы белән тулысынча тәэмин ителүләренә дә карамастан, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны республика буенча уртача күрсәткечләрдән түбәнрәк. Кама Тамагы, Яңа Чишмә һәм Актаныш районнары башлыкларына әлеге мәсьәләләргә аерым игътибар итүләрен сорыйм.

ГТО системасын актив кулланышка кертү физик культураны һәм спортны үстерүгә зур этәргеч бирә. Бүгенге көндә ГТО мәгълүмат системасында республиканың һәр дүртенче кешесе теркәлүгә дә карамастан, әлеге нормативларны үтәгән кешеләр саны буенча безгә ил күләмендә беренчеләр сафында булу өчен бик күп тырышырга кирәк әле.

Спорт министрлыгы, муниципалитетлар башлыкларының бурычы – теләге булган һәр кешегә ГТО нормативларын бирүдә үз көчен сынап карар өчен тиешле барлык шартларны булдыру. Әлеге чаралар даими нигездә уздырылырга тиеш һәм һәркемгә алардан файдалану мөмкинлеген бирү зарур.

Физик культураны һәм спортны популярлаштыруга Татарстан командаларының, шул исәптән ил чемпионы – «Зенит-Казан» волейбол клубы, ВТБ Бердәм лигасы җиңүчесе – «Уникс» баскетбол клубы, Континенталь хоккей лигасының көмеш призеры – Казанның «Ак Барс», Россия Кубогы көмеш призеры – «Синтез» су полосы клубы, шулай ук күп тапкырлар чирәмдә хоккей буенча ил чемпионнары – «Динамо – Ак Барс» ир-атлар һәм хатын-кызлар командаларының уңышлары зур этәргеч бирә.

Без шулай ук Татарстан спортчыларының җиңүләре белән горурланабыз. Алар бильярд спорты буенча дөнья чемпионы Диана Миронова, бу елның Россия чемпионнары һәм вице-чемпионнары: стендка ату буенча Сергей Демин, авыр атлетика буенча Регина Шәйдуллина, суга синхрон сикерү буенча Александр Белевцев. Безнең спортчыларыбыз бүген залда. Сезгә хезмәтегез өчен зур рәхмәт сүзләрен җиткерәбез һәм яңа җиңүләр көтеп калабыз!

Республика – спорт төбәге, ә Казан шәһәре – спорт башкаласы дигән исемнәрен дәлилләп тора. Киләсе елда республикада тарихта беренче тапкыр ике зур мультиспорт чарасы – Киләчәк уеннары һәм БРИКС уеннары уздырылачак. Әлеге ярышларны югары дәрәҗәдә үткәрергә кирәк.

Татарстанда зур чаралар уздыру, тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән илкүләм проектларны һәм республика программаларын гамәлгә ашыру белән беррәттән, без барлык социаль йөкләмәләрне тулысынча үтибез һәм адреслы социаль ярдәм күрсәтүне дәвам итәбез.

Инвалидларга, өлкән яшьтәге кешеләргә, балалы гаиләләргә һәм атаана каравыннан мәхрүм калган балаларга булышу – безнең төп бурычларның берсе.

Хөрмәтле депутатлар!

Кадерле ватандашлар!

Алдыбызда төрле өлкәләрдә күп бурычлар тора. Без аларны бергәләп, һичшиксез, үтәрбез дип ышанам. Безнең көчебез – тырыш булуда, талантлы кешеләребездә, өлкәннәрне хөрмәт итүдә, туган илгә булган мәхәббәттә, гаилә кыйммәтләрен һәм мәдәни традицияләрне саклауда.

Без мең еллык тарихы һәм бай мәдәни мирасы булган илдә яшәвебез һәм эшләвебез белән бик нык горурланабыз.

Безнең көч – күпмилләтле халкыбызның бердәмлегендә! Бергә булганда, безгә бернинди кыенлыклар да куркыныч түгел! Без, һичшиксез, җиңәчәкбез! Без бергә! Без булдырабыз!

ХӨРМӘТЛЕ РӘИС, ХӨРМӘТЛЕ ДЕПУТАТЛАР...

ТР Дәүләт Советында

Парламентның 47 нче утырышыннан чыктым да уйга калдым. Депутатларның күбе татар булса да, мөнбәр артына чыгып баскач: «Хөрмәтле Рәис, хөрмәтле депутатлар...» – диюдән узмыйлар. Татар телләре саймы соң? Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, аның урынбасары Марат Әхмәтовның, депутатлар Камил Нугаев, Азат Хамаев, Ркаил Зәйдулланың һәм тагын бер-ике бөртек депутатның үз ана телләрендә сөйләшүләре кайчак «гомуми кагыйдә»дән искәрмә кебек кабул ителә. Шул ук вакытта Татарстанда ике дәүләт теленең дә яшәргә тиешлеге турында җан атып сөйлибез. Татарстан Рәисе Юлламасында да бу хакта аерым әйтте.

Җәмәгать судьяларын сайлаганда, ирексездән, Туфан ага искә төшә. Судьялык вазыйфасына тәкъдим ителгән татарлардан: «Татарча беләсезме?» – дип сорамый калмый иде ул. Бу сорау утырыштан утырышка кабатлангач, депутатлар елмая да башлаганнар иде. Ә татар теленең бүгенге хәле турында уйланганда бер дә елмаясы килми.

Чыгышларның бисмилласы булган «Хөрмәтле Рәис, хөрмәтле депутатлар...» дигән сүзләр генә «күңел юаткычлары» кебек кабул ителә.

Сессия утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләр дә, нигездә, үз законнарыбызны Федераль закон кысасына куып кертүгә багышлана. Киләсе елга Татарстан бюджеты нинди булыр, бетмәс-төкәнмәс чикләүләр, Украинада барган махсус хәрби операция казнага нинди йогынты ясар дигән уйлар күңелне бимазалап торган иде, әмма утырышта бу хакта әллә ни сүз булмады. Чөнки Россия Думасы Федераль бюджет турында закон кабул итмичә, үзебезнеке турында тиешенчә кайгырта алмыйбыз. Бюджет турында закон проекты Дәүсовет утырышына октябрьдә генә керәчәк.

Бу уңайдан утырышта күтәрелгән бер мәсьәләне телгә аласы килә. Дәүсовет Россиянең фән һәм югары белем министры Валерий Фальков исеменә мөрәҗәгать әзерләнгән. Аның белән парламентның Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов таныштырды. Мөрәҗәгатьнең асылы мондый: Татарстанда студентларның дистәдән артык спорт-сәламәтләндерү базалары бар. Әмма аларның шактые инде тузган. Безнең югары уку йортлары «федераль» исәпләнгәч, базаларны төзекләндерү өчен акчаны да федераль бюджеттан бирсеннәр.

Мөрәҗәгать хупланды, алай гына да түгел, парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, федераль үзәк белән хезмәттәшлектән бик үк канәгать булмавын белдереп, депутатларны, комитет рәисләрен шелтәләп тә алды. Төрле инициативалар белән Думага чыгабыз, мөрәҗәгатьләр юллыйбыз, аннан соң аларның язмышы белән бөтенләй кызыксынмыйбыз. Федераль органнар белән күбрәк эшләргә кирәк. Фәрит әфәнденең төп фикере әнә шундыйрак иде. Үз законнарыбызны федераль законнарга яраштырып утыру, гадәттә, зур бәхәс куптармый. Бер илдә уртак кагыйдәләр белән яшисең инде ул. Ә менә мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин чыгышы депутатларда шактый сораулар тудырды. Мәгариф үсеше программасының ничек тормышка ашырылуы турында сөйләде министр. Нотыгы бик әчтәлекле, мәгълүматлы иде, тик кайбер депутатларга артык шома кебек тоелды ул. Асылда барысы да ал да гөл түгел бит. Бездә ел саен күпме мәктәп, балалар бакчалары ачыла. Әгәр туксанынчы еллар кабатланып, алар бушап калса, нишләргә? Хәтерләсәгез: балалар туу кимегәч, яшәүнең рәте киткәч, белем алу һәм тәрбия учреждениеләренә баручылар азайды һәм бушап калган бинаралар төрле офисларга әйләнеп калган иде.

Әлбәттә, мондый «заман проблемасы»н министр Һадиуллин гына хәл итә алмый, алай да Илсур әфәнде, андый хаталарга юл куелмас, дигән фикердә. Бездә әле укытучыларга да кытлык икән. Хәзерге көндә мәктәпләргә 425 укытучы җитми, нигездә Казанда. Министр әйтүенчә, «кытлык мәсьәләсе»н бераз хәл итү өчен мәктәпләргә югары курсларда укучыларны чакыра башлаганнар. Укытучы һөнәренең абруе төшү хезмәт хакының түбән булуы һәм яшь белгечләрнең торак белән тәэмин ителмәвенә дә бәйле. Депутат Азат Хамаев, министрлыкның үз торак фонды булырга тиеш, ди. Депутатлар студентларның стипендиясен күтәрү турында да сүз кузгатканнар иде, әмма министр югары уку йортлары федераль Үзәк карамагында булганга, стипендия күтәрү Мәскәү эше икәнен әйткәч, тынычландылар тагын.

Депутат Фәтбир Сафинның чыгышы күңелгә кереп калды. Ул заманында Көнбатышның безгә либерализацияне көчләп тагуын, мәгариф өлкәсенә күз йомып «Болонья системасы»н кертүгебезне искә төшерде. «Әлеге үзгәрешләр үзләрен акладымы?» – диде. Депутат фикеренчә, мәгариф өлкәсе ул – белем бирү генә түгел, ә идеология дә. Депутатларны мәктәпләрдә татар сыйныфларының саны, милли дәреслекләрнең ни өчен җитмәве, Россиянең яңа тарихы турындагы дәреслекләрнең ни өчен рус телендә генә булуы һәм башка бик сораулар кызыксындырды. Бүген милли мәгариф мәсьәләсендә бик әчкә кереп тормыйбыз, хәзергә хөрмәтле җитәкчеләр дә, хөрмәтле депутатлар да, сез дә, без дә уйлана торыйк.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

18 сентябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Соотечественники» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» и «Учимся вместе» 0+
17.30 «Гаилә учагы» 16+
18.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Витязь». Прямая трансляция 6+ 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 12+
00.00 «Соотечественники». Надежда Дурова, или Штаб-ротмистр Александров из Елабуги 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Сәлимә Әминова турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Яшьләр тукталышы» 6+
17.30 «Адымнар» 16+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Калеб» 6+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
02.40 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.50 Новости
07.05, 21.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Самый лучший тренер в мире – Павел Фёдорыч Садырин!» Документальный фильм 12+
11.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
12.30 Специальный репортаж 12+
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
13.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Енисей-СТМ» (Красноярск) – «Металлург» (Новокузнецк). Прямая трансляция
15.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Тюмень» – «Родина» (Москва). Прямая трансляция.
18.00 «Громко» Прямой эфир
18.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Локомотив» (Ярославль). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Верона» – «Болонья». Прямая трансляция
00.40 Борьба. Чемпионат мира. Трансляция из Сербии 12+
01.10 Смешанные единоборства. UFC. Алекса Грассо против Валентины Шевченко. Трансляция из США 16+
02.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Коринтианс» – «Гремио». Прямая трансляция
05.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Сергей Пускепалис. «НАПАРНИКИ» (S) 16+
00.55 «ВИРУС» (S) 16+
03.15 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40 «Понять. Простить» 16+
11.45 «Порча». «Дворняга». «Роковая встреча» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ИДЕАЛЬНОЕ ЗАБЛУЖДЕНИЕ» 16+
23.05 «Понять. Простить» 16+
00.15 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Преступления страсти» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «АНАКОП». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». «ПО СТАРОЙ ЛЕГЕНДЕ» 12+
12.35, 13.25, 15.05, 03.20 «БРАТСТВО ДЕСАНТА». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25, 17.15 «БРАТСТВО ДЕСАНТА». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
18.00 «Битва оружейников». Документальный сериал. «Истребители. МиГ-29 против F-16». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих». Премьера! 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал 12+
23.45 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 12+
02.30 «Без свидетелей. Павел Фитин против Шелленберга». Документальный фильм 12+

19 сентябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». Телесериал (татар телендә)16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Ватандашлар» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» и «Учимся вместе» 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ». Телесериал 12+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Башваткыч» 12+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Ко Дню оружейника. Премьера. «Огневое превосходство Аркадия Шипунова» 12+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 08.30, 14.40 Новости
07.05, 19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Летний биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Индивидуальная гонка. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
10.25 «Легендарные клубы» 12+
11.25 Специальный репортаж 12+
11.45 Летний биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Индивидуальная гонка. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
13.25 «Есть тема!» Прямой эфир
14.45 Футбол. FONBET Кубок России. «Краснодар» – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция.
17.00 Футбол. FONBET Кубок России. «Пари НН» (Нижний Новгород) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Милан» (Италия) – «Ньюкасл» (Англия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. ПСЖ (Франция) – «Боруссия» (Дортмунд, Германия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Сити» (Англия) – «Црвена Звезда» (Сербия) 6+
02.55 Борьба. Чемпионат мира. Трансляция из Сербии 12+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Америка Минейро» – «Брагантино». Прямая трансляция

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Сериал «НАПАРНИКИ» (S) 16+
00.55 Детектив «ВИРУС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40 «Понять. Простить» 16+
11.45 «Порча». «Рыбаки». «Лавина» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ТРЕБУЕТСЯ МАМА» 16+
23.10 «Понять. Простить» 16+
00.15 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Преступления страсти» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «БРАТСТВО ДЕСАНТА». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». «ВОЗВРАЩЕНИЕ БЕКАСА» 12+
12.35, 13.25, 15.05, 03.30 «БРАТСТВО ДЕСАНТА». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+
15.00 Военные новости. 16+
15.25, 17.15 «БРАТСТВО ДЕСАНТА». Телесериал. 7-я и 8-я серии 16+
18.00 «Битва оружейников». Документальный сериал. «Военно-транспортная авиация. Ил-76 против С-17». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Самолёт F16. Обречённое «супероружие» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал. Премьера! 12+
23.45 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 12+
02.50 «Легендарные самолеты. Ту-95. Стратегический бомбардировщик». Документальный фильм 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Урта Идел авыл электр челтәрләре төзелеше» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең биналарны һәм корылмаларны эксплуатацияләү хезмәте җитәкчесе **Фәттахов** Мәхмүт Габделхәмит улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итү һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире **Беляков** Роман Юрьевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Академия коллективының фәнне үстерүдә аеруча мөһим казанышларга ирешүе, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен **«Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Зәй шикәре» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты **Баһаутдинов** Дамир Хәбир улы, «Сабаның «Мелиорация» күчмә механикалаштырылган колоннасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Кәбиров** Фаяз Сәитгали улы, Фәйзи Галиев исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш агрономы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Нәфиков** Газинур Камил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бозау карауччысы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Ермакова** Эльвира Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Бускин** Сәлим Якуп улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ХӘРӘКӘТ КОТКАРА

Россиядә яшәүче һәр ун кешенең берсе буын авыруларыннан интегә. Шул ун кешенең берсе әлеге авыру аркасында ахыр чиктә инвалид кала. Рәсми саннар чәчләр үрә торырлык. Буын авыруларын ничек кисәтеп була? Операциядән куркырга кирәкме?

Табиб-ревматолог Елена ВАСИЛОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Буын авырулары бүген ни сәбәпле шулай арта?

– Соңгы арада буын авырулары яшәрә бара. Хәзер ревматологка 25–35 яшьлек кешеләр дә мөрәҗәгать итә. Соңгы арада буын авыруларының шулай еш таралуы, бигрәк тә яшәрүе, иң беренче чиратта, дөрес тукланмауга, зарарлы азыктөлеккә өстенлек бирүебезгә, даими рәвештә стресста яшәвебезгә бәйле. Коронавирус та моңа үз өлешен кертте. Буын авырулары хәрәкәт аз булу, организм өчен кирәкле витамин, аксым, минераллар җитмәү аркасында да аза ала.

:: Буын авырулары арасында иң киң таралганы – остеоартроз турында без нинди белеп торырга тиеш? Ул артриттан нәрсәсе белән аерыла?

– Әлеге чир вакытында буынның бөтен өлешләре зарарлана. Иң беренче чиратта кимерчәк сафтан чыга. Кан тамыры тирәсендәге мускуллар, буыннарның синовиаль тышчасы да зарарлана. Яшь барган саен остеоартроз килеп чыгу ихтималы да арта. Ул нәселдән дә күчә ала. Мускуллар зәгыйфь булса, организмда гормональ тайпылыш күзәтелсә, остеоартроз килеп чыгарга мөмкин. Артык авырлык та куркыныч. Һәр артык килограмм буыннарга зур басым ясый. Тез, оча, бот сөякләре аеруча зыян күрә. Артроз вакытында кимерчәк зарарлана, буын тукымасы үзгәрә. Артрит вакытында буыннар турыдан-туры борчымаска да мөмкин. Кеше үзендә хәлсезлек сизә, тән температурасы күтәрелә, ревматоидлы төерчекләр пәйда була, мускуллар зәгыйфьләнә.

:: Нинди билгеләр вакытында кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк?

– Әгәр буын турысы, бигрәк тә умыртка баганасы тирәсендәге өлеше авыртса, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Әгәр буын кызарып, шешеп чыкса, тән температурасы күтәрелсә, ашыгырга кирәк. Хәрәкәт итә башлаганда авырту борчыса да чаң сугарга җирлек бар. Буын авырулары вакытында тәнгә тимгелләр чыгарга, температура төшмичә азапларга, кеше кисәк ябыгырга да мөмкин.

:: Бармак шартлатсаң, буыннарга тоз утыра, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Тик торганда бармак шартлату зыянлы, билгеле. Ул буын тукымаларына зыян салырга мөмкин.

:: Күпләр буынга операция ясатудан курка, гомерлеккә йөри алмаслык хәлдә калырмын дип шүрли. Андыйларга ни диярсез?

– Теләсә кайсы операция – организм өчен зур стресс. Аның алдыннан курку, шүрләү дә – табигый хәл. Буыннарга операция буыннар бик нык зарарланганда, дарупарның файдасы тимәгән, авыртуга түзә алмаган, инвалид калу куркынычы зур булган җитди очракларда гына ясала. Операциянең ни дәрәҗәдә уңышлы булуы буыннарның ни дәрәҗәдә ялкынсынган булуына, кешедә шикәр чире, артык авырлыгы бармы-юкмы, аның моңарчы инсульт, инфаркт кичергәнме-юкмы икәнлегенә бәйле. Операциядән соң тернәкләнү чорын да тиешенчә узу мөһим.

:: Буын авыруларын ахыргача дәвалап булмый, алар гомерлек, ахыргы көнеңә кадәр гормональ дарулар эчеп торырга туры киләчәк, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә...

– Мин һәрчак әйтә киләм: буын авырулары – хроник рәвештә узучы җитди чир. Алар дәвалауга бирешми дигән сүзләр дөреслеккә туры килми. Безнең төп максат – авыруны басып, ремиссия чорын озаккарак сузу. Моның өчен яшәү рәвешен үзгәртергә: дөрес тукланырга, туйганчы йокларга, стресстан сакланырга, табиб кушканнарны төгәл үтәргә кирәк. Гомер буе гормональ дарулар эчеп торырга туры киләчәк дигән сүз – уйдырма. Әлеге төр препаратлар кайбер буын авырулары вакытында гына языла.

shutterstock.com

БУЫН АВЫРУЛАРЫННАН САКЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

➤Буын авыруларын кисәтү өчен һәрчак хәрәкәттә булырга, күп йөрергә кирәк. Буын авыруларын дәвалаган вакытта да физик активлык коткара. Әмма күнегүләр дөрес сайланган булырга тиеш. Әйтик, тез буыннары авырткан кешегә чүгәләргә, сикерергә, йөгерергә ярамый. Шуңа күрә буын авырулы кешеләргә күнегүләрне ятып яки утырып кына ясарга кирәк.

➤Күп кенә буын авырулары нәселдән күчә. Шуңа күрә нәселендә ревматоидлы артрит, Бехтеров авыруыннан, псориатик артриттан интеккән кешеләр булса, даими рәвештә табибка күренеп, анализлар тапшырып торырга кирәк.

➤Буын авыруларыннан саклану өчен дөрес туклану, гәүдә авырлыгын һәрчак контрольдә тоту да мөһим.

➤Тәмәке тарту кебек начар гадәтләрдән баш тарту да хәерле.

➤Кандагы гемоглобин, ферритин күләмен, СОЭ дәрәҗәсен дә гел контрольдә тотарга, Д витамины эчеп торырга кирәк.

➤Эчәклек – кешенең иң зур иммун органы. Буын авырулары пәйда булмасын өчен аның, шулай ук бавырның да сәламәт булуы кирәк.

Киңәш

Баш авыртса...

Баш авыртуның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә аны дәвалау алымнары да аерыла.

✓Баш организмга су җитмәсә дә авыртырга мөмкин. Аннан лимон телеме салынган бер стакан чиста су ярдәм итәргә мөмкин. Табиблар көн саен 6 стакан су эчәргә куша. Магний кан тамырларын йомшартып, организмны баш авыртуыннан саклый ала.

✓Чикләвекләрдә магний күп. Ул да баш авыртудан коткара. Имбирлы чәй, маринадланган имбир дә ярдәм итәр.

✓Бәрәңгедә калий күп, шуңа ул да баш авыртуыннан ярдәм итә. Аны мичтә әзерләсәң, бигрәк тә яхшы. Ул натрийкалий микъдарын җайга сала, организмдагы су күләмен контрольдә тота.

Үт куыгы ялкынсынса

Үт куыгы ялкынсынганда кабак сөте ярдәмгә килә. Аны әзерләү өчен 50 г чистартылган кабак төшенә су (80 мл) һәм шикәр комы (20 г) салып изегез. Файдалы «сөт»не ач карынга эчәргә кирәк. Бавыр өчен кабак орлыклары төнәтмәсе дә файдалы. Аны ясау өчен 250–500 г орлыкка 0,5–1 л кайнар су салып, 2 сәгать төнәтегез. Төнәтмәне 1 сәгать дәвамында эчәргә кирәк.

Хәл кертә торган төнәтмә

Шифалы төнәтмә ясау өчен 2 бал кашыгы кипкән гөлҗимеш өстенә 0,5 литр кайнап кына чыккан су коегыз да, тастымалга төреп, төнгә калдырыгыз. Иртән бер стакан төнәтмәгә 1 бал кашыгы бал өстәп, эчеп куегыз. Төшке яки кичке аш алдыннан калганы белән сыйланыгыз. Иммунитетыгыз сынатмас.

Үзем сынадым

Герпестан котылдым

Аз гына туңдыммы, герпес чыгып тилмертә. Соңгы арада татлы тамырның (солодка) файдасын күрә башладым. Аны порошок итеп изәм дә шуңа кайнар су өстим. Кые ботка халәтенә җиткәч, герпес чыккан урынга сөртәм. Моны төнгә каршы, йоклар алдыннан эшләп, иртән юып алырга кирәк.

Әминә ВӘЛИЕВА. Апас

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Бакчачыга

Агачлар да «җим» сорый

Җәй буе җимеш биргән яки быел ял иткән агач-куаклар киләсе елда мул уңыш белән сөендерсен өчен хәзердән үк хәстәрен күрегез.

●**АЛМА БЕЛӘН ГРУША**
Аларны уңышларын җыеп бетергәч тукландырырга кирәк. 1,5 стакан суперфосфат һәм 1 стакан калий сульфаты белән ашларга мөмкин.

●**ЧИЯ ҺӘМ ТӨЧЕ ЧИЯ**
Әлеге агачларны сентябрь аенда 1 стакан суперфосфат һәм 3 аш кашыгы калий сульфаты белән тукландырабыз.

●**КАРЛЫГАН**
Әлеге куак агачлар белән чагыштырганда бик кечкенә күренсә дә, аппетиты зур, ул ашарга бик ярата. Аны беренче тапкыр сентябрь ахыры – октябрь башында 0,5 стакан суперфосфат һәм 2/3 стакан калий сульфаты белән тукландырырга киңәш ителә. Икенче тапкыр октябрь ахырында тукландырыла: төбенә ярты чиләк черегән тирес салырга кирәк.

●**КУРА ҖИЛӘГЕ**
Кура җиләге тукландыруга бик талымлы түгел. Аның төбенә октябрь ахырында 1 кв. метрга 3 кг исәбеннән тирес кертү дә җитә.

●**СЫРГАНАК**
Сырганак та бик нәзберек түгел, аны җәй буена бер тапкыр азот белән тукландыру да җитә. Бакчачылар исә җимешләре җыеп алганнан соң аны көз көне 0,5 стакан суперфосфат белән тукландырырга киңәш итә.

Алда санап үтелгән ашламаларның барысы да бертөрле кулланыла. Башта аларны агач-куак төбендәге «түгәрәк» буйлап чәчеп чыгарга һәм аннары яхшылап су сибәргә киңәш ителә.

КАМЫР ҖИЛ ЯРАТМЫЙ

Раилә АХУНОВА пешергән ризыклар янынннан битараф кына үтеп китеп булмый. Ул үзе белгәнне башкалар белән дә уртаклаша.

– Саба районының Явлаштау авылы кызы мин, – ди Раилә. – Ирем белән бер сыйныфта укыдык. Гаилә корып, Казанда яшибез. Күп еллар ит сатучы булып эшләдем. Бермәлне, шул ит саткан җиргә, өйдә ярымфабрикатлар әзерләп алып килә башладым. Кеше ала, ризыкны ошата, мактый. Минә шунда: «Нигә әле ризык әзерләү буенча эшләмим соң?» – дип, үз эшемне ачарга булдым, – ди ул.

Аш-суга үңганлыгы әнисеннән килә икән. Ярымфабрикатлар белән генә калмый, сораган кешегә пирог, бәлешләр дә әзерләп бирә.

– Никах-туйларга казлар да пешереп-бизәп бирәм. Аш, бәйрәм уздыручыларга табыннар әзерлим. Кабымлыклар да ясый башладым. Кешеләр үтенече буенча, бик теләп, өстәл корам, букетлар да ясыйм. Интернетта кием кибетем дә бар. «Ничек өлгерәсең?» – диләр. Вакытны дөрес итеп бүләм һәм эшләү теләгем зур. Әгәр теләк бар икән, таулар күчерәсең, – ди Раилә. – Без – ризык пешерә белә торган буын. Ә менә яшьләр хәзер плитә алдында торуны яратмый. Вакытларын башка кирәкле эш белән уздыралар. Ә ризыкны сатып алалар. Өйдә пешергән ризык тәмле инде ул. Кешегә ризык әзерләүне дә яратып башкарырга кирәк. Хәзер кул үзеннән-үзе эшли. Ризыкларымны яратып ашаучы кешеләрем бар. Аларның матур сүзләре канат куя.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Раилә Ахунованың шәхси архивыннан

АЛМА БЕЛӘН КОРТ ПИРОГЫ

Камыр өчен (3 пирогка) 1 кап маргарин, 1 кап атланмай, 2 йомырка, 220 грамм сөт, 3 аш кашыгы каймак, 1 чәй кашыгы чүпрә, тоз, шикәр комы һәм он кирәк була.

Эчлек өчен (бер пирогка) 800 грамм алманы алдан турап, шикәр комы һәм лимон согы белән болгатып куябыз. 400 грамм корт кирәк була. 2,5 стакан иләнгән онга бераәр аш кашыгы тоз һәм шикәр комы кушабыз. Ике кап майны уып, валчык ясыйбыз. Җылы сөткә бер аш кашыгы шикәр комы, бер чәй кашыгы чүпрә салып күпертергә куябыз. Аннары шуңа май һәм каймак, йомырка салып, камыр басабыз.

Пирог болай эшләнә. Табага камыр җәеп, шуңа 200 грамм корт салабыз. Өстенә бераз шикәр комы, 4–5 аш кашыгы атланмай, калган кортны алмага кушып болгатып, табага салабыз. Аннары аның өстенә тагын 3 аш кашыгы атланмай, шикәр комы, ванилин сибеп, өстен каплыйбыз. Әлеге пирогны мичтә 40 минут пешерәбез.

БӘЛЕШ ПЕШЕРГӘНДӘ ИСТӘ ТОТ

✓Бәлеш тишелмәсен өчен, камырга сөт ризыклары кушмагыз.
✓Кешеләр бәлешнең төбен тишә, ә мин өске яктан тишек калдырам.
✓Камыр җил яратмый, озак басканны ярата.
✓Камырны кичтән басып, пакетка салып калдырсаң да ярый.

Саклап куй!

Бик тәмле мантый камыры

Тәския ВАГЫЙЗОВА рецепты

Мондый камыр чебурек, пилмән, мантый ясарга яхшы.
1 стакан кайнар суга тоз, бер стакан он салып тиз генә болгатам да, ике аш кашыгы сыек май, 2–3 йомырка өстәп, он кушып, камыр басам һәм бераз ял иттерәм.
Камыр пластилин кебек булырга тиеш.

Сула гына

Психология

Күтелмәгән күңелсез хәл, стресс, курку, каеф кырылу вакытында гадәттә сулыш өзелә башлый һәм без тирән итеп сулауны онытып, өстән-өстән генә сулый башлыйбыз. Ә бу исә эмоциональ киеренкелекне тагын да арттырып, стрессны тагын да тирәнгә җибәрергә мөмкин. Мондый вакытта түбәндәге җиңел генә күнегүләр ярдәмгә килер.

«4-4-4». 4 секунд дәвамында тирән итеп сулыш алып, аны 4 секунд тотып торырга һәм шундый ук вакыт дәвамында әкрен генә сулышыңны чыгарырга кирәк. Әлеге күнегүне тынычланганчы 5–10 тапкыр кабатлау да җитә.

«Шар корсак». Борын белән тирән итеп, корсак шар сыман тулырлык итеп сулыш алабыз. Аннары сулышны авыз аша акрын гына корсак шиңәрлек итеп чыгарабыз. Шунысына игътибар итәргә кирәк: сулыш нәкъ менә корсакка алынырга тиеш, ә күкрәккә түгел.

«Торба». Муен һәм иңбашларыгызны киеренкелектән арындырыгыз. Икегә кадәр санап, авызны япкан халәттә борын белән сулыш алыгыз. Аннары иреннән «торба» ясап, 4кә кадәр санап, сулышны акрын гына чыгарыгыз. Әлеге күнегүне 15 тапкыр ясарга киңәш ителә.

Белеп тор!

КИШЕРЕ ДӘ КИШЕРЕ!

Быелгы иң тәмле һәм чыдам кишер сортларын ачыклаганнар. Түбәндәге сортлар аш, салат, десерт һәм соклар әзерләү өчен иң яхшылары дип танылган. Киләсе ел өчен саклап куйсагыз да була.

«Детская сладкая». Әлеге сорт уртача уңыш бирә һәм татлылыгы белән аерылып тора. Озынлыгы 20 сантиметрга кадәр, тәсе җете. Үзәге һәм тышы чагыштырмача йомшак, шунлыктан чи килеш куллану өчен менә дигән.

«Маэстро F1». Иртә өлгерә торган гибрид күпчелек климатик зоналарга туры килә. Авыруларга бирешми, пешерү, кышка әзерләү һәм чи килеш ашау өчен дә яхшы.

«Император». Соң өлгерә торган әлеге сорт тәменең «байлыгы», тыгыз, баллы һәм хуш исле булуы белән аерылып тора. Тиешле шартларда 9 айга кадәр саклана. Туфракта дым артык булганда да ярылмый һәм черемы.

КӨН ДӘ БЕР СОРАУ

Көндәлектә нинди генә сораулар белән очрашмыйбыз. Монысы ничек, тегесе ничегрәк дип баш ватар урынга, динебезгә мөрәҗәгать итү кулайрак. Бу юлы да сәхифәбезне укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга багышларга булдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ белән сорауларга җавап эзләдек.

?Соңгы арада бернәрсәдән дә ямь тапмыйм. Күңел төшенкелегеннән ничек котылырга?

– Күңел төшенкелегенә бирелү адәм баласына хас нәрсә. Әмма пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кайгырмагыз! Мөселманның кайгыруына шайтан шатлана», – дип кисәтә. Бу – шайтанның бер коралы. Рухны төшермәс өчен, галимнәрнең вәгазьләрен тыңларга, дәресләргә йөрергә, узалдына яхшы максат куярга кирәк. Төшенкелек сихер аркасында булса, үзеңне өшкертергә кирәк.

?«Аллаһы Тәгалә күктә» дип уйлау дөресме?

– Галимнәр: «Аллаһы Тәгалә вакыттан һәм урыннан өстен», – ди. Ягъни Аллаһы Тәгалә вакытка да, урынга да бәйле түгел. Чөнки Ул – аларны үзе бар итүче. Шуңа күрә: «Аллаһы Тәгалә кайда?» – дип сорау дөрес түгел. Имам Мәлик: «Мондый сорау биргән кешене мәчеттән куып чыгарыгыз», – дигән.

?Иренем ошамый. Азрак кабартасы, үзгәртәсе килә. Ислам динендә пластик операцияләр рөхсәт ителәме?

– Кабартасы килгән урыннар күп булыр инде ул. Үзгәртәсе, зурайтасы, кечерәйтәсе... Аллаһы Тәгалә биргән тән, кыяфәткә риза булырга кирәк. «Кем чәчкә чәч ялгый, каш ясый һәм ясата, Аллаһы Тәгалә аларны ләгънәт кылды», – диелә хәдисләрдә. Пластик операцияләр кешенең саулыгына бәйле булса гына ярый. Әйтик, кешенең борыны суламый, ди, борынга операция ясата. Бу очракта үзгәртү нияте түгел, сулышны кайтару нияте.

?Диннән көлә торган мәзәкләр сөйләү яисә тыңлау гөнаһмы?

– Диннән көләргә тырышкан кешеләр элек тә булган. Соңрак алар үзләре дә мәсхәрәгә калган. Нух пәйгамбәрнең (г.с.) хатыны иренең көймә ясавыннан көлгән, әйтик. Диннән көлә торган мәзәкләр, тамашалар, җырлар, чыгышлар, спектакльләр, сүзләр – хәрам күренешләр.

?Бурычлы үлмәс, диләр. Әмма кайберәүләр шул бурычлары аркасында үз теләге белән теге дөньяга да китеп бара. Моннан соң мәрхүмнең бурычлары кемгә йөкләнә соң?

– Кеше үлә икән, аның бурычын варислары түләргә тиеш. Еш кына моңа варислар – балалар әллә ни игътибар бирми. Үлгән кешенең мал-мөлкәте кала икән, иң беренче чиратта Аллаһы Тәгалә каршында булган бурычлары түләнергә тиеш. Икенче булып кешеләр каршында булган бурычлар түләнә. Аннан соң гына мирас малын бүләргә ярый.

?Никахлашканчы балага узып, аннан никах укытканнан соң туган бала зинадан туган бала булып саналмасмы?

– Никахлашканчы балага уза икән, бу бала, билгеле, зинадан туган бала булып санала.

ГАРӘП ҺӘМ КАРАК БЕЛӘН БУЛГАН ХӘЛ

Гыйбрәт ал!

Кечкенә авылларда зиратта тәртип саклау җиңелрәк, ди унбиш ел Әтнә районының Кышлау авыл җирлеге рәисе вазыйфасын башкарган Рәхинә Шакирова. Бу җирлеккә өч авыл: Кышлау, Кызыл Утар һәм Яңа Әҗем керә, бергә 500гә якын кеше яши.

– Төптән уйласаң, безгә үзебездән чыгып киткән кешеләр кайта. Авылдан читкә китүчеләрнең йә ирен, йә хатынын монда җирләргә мөмкиннәр. Ул авыл советы һәм мулла рөхсәте белән эшләнә. Мин җирле үзидарәдә эшләгәндә, мәсәлән, кеше шалтырата да, шундый-шундый мәетне алып кайтырга мөмкинме, дип хәбәрләшә. Мондый очракта без каршы килмибез. Аның да нәсел-нәсәбе бар бит. Шуңа күрә авылга читтән мәет кайтартмау ягында түгел мин. Дөрес, чит диндәге кешеләрне кертмибез. Бу мәсьәләдә авылда бер дә каршылык булганы юк, – ди әле күптән түгел генә лаеклы ялга чыккан Рәхинә Шакирова. – Ә акча мәсьәләсенә килгәндә, мин эшләгән 2005 нче елларда, мәсәлән, зиратларны карау өчен бик аз күләмдә салымнан кергән акча гына бүлеп бирелә иде. Шуңа күрә зиратта тиешле тәртипне саклау читен булды. Тимер капка-коймаларны да, 2013 елда Татарстанда үзара салым гамәлгә кереп, шул акчага каберстаннарны карап тору мөмкинлеге тугач кына куя башладылар бит әле. Читтән мәет алып кайткан кешеләр еш кына: «Сезгә ничек ярдәм итә алабыз?» – дип сорыйлар. Зират чистартырга кайтып йөри алмыйбыз дип, мәчеткә акча калдыралар. Әнә шуннан башланган эш ул. Кечкенә авыл зиратларына читтән елына 1–2 кеше кайта. Алар, хәлләренә карап, 3–5 мең сум акча калдыра. Шуннан да күп түгел. Шәхсән мин моңа каршы түгел. Авыл картая, хәзер зиратларны карап торуны өмәләр белән генә җиңә торган түгел. Шуңа күрә бу күпмедер ярдәм булып тора.

Хәер, зиратларны чиста тоту өчен акчадан бигрәк, бердәмлек кирәк. Кышлау җирлегендәге кебек, мәсәлән.

– Берничә ел элек авылда зур өмә оештырдык. Иң элек социаль челтәрләрдәге төркемнәрдә бу хакта хәбәр салдым. Иске агачларны кисәргә, аларны читкә чыгарырга кирәк, дип аңлаттым. Намусы булган кеше өмәдән читтә калмады. Кайта алмаучылар, миннән өлеш булсын дип, сәдака җибәрделәр. Ай буе зират чистарттык без. Йорт башыннан ике көн өмә үткәрдек. Кеше калган көннәрдә дә эшли икән, мәсәлән, буш вакытында ун көн зиратка килсә, аңа өмәгә кайта алмаган кешеләр җибәргән акчадан «кул җиле» түләдек. Күп кеше алмады да аны. Һәр авылның зират өчен җаваплы кешеләре бар. Алар ел дәвамында кирәкле эшләрне оештыра. Рәис әйткәнне дә көтмиләр. Барысы да эшне дөрес оештыра белүдән, авыл җирлегеннән һәм халыкның үзеннән тора. «Ватсап»та эш барышын, кемнәр катнашуын, ә кемнәр әлегә читтәрәк калуын язып бару да яхшы нәтиҗә бирә. Бәхәсләшмичә генә, әлбәттә. Кешегә кешечә мөнәсәбәттә булсаң, беркем дә уртак эштән читтә калмый. Бүген зиратларыбыз чиста, – ди Рәхинә Шакирова.

«Бурычлы аш кирәкми»

Мөдәррис хәзрәт Гыймранов фикеренчә, динне үзебез авырайтабыз.

– Шәригать буенча мәеткә карата башкарылырга тиешле дүрт шарт бар. Болар – юу, кәфенләү, җеназа намазы уку һәм ләхет алынган кабергә күмү. Менә шулар эшләнсә, туганнарның мәет өстеннән хакы төшә. Интернетта мәетне юган өчен акча сорыйлар дип, күп кенә видеолар таралды. Имеш, кешегә болай да кайгы килгән. Җәмәгать, әгәр әтиегезне, әниегезне, туганыгызны үзегез юсагыз, бер тиен түлисе юк. Аны хәзрәт тә, имам да, абыстай да эшләргә тиеш түгел. Тиешлеге буенча да, балаларга әти-әниләрен үзләре юу каралган. Юк икән, кешегә мөрәҗәгать итәләр, ә бу – хезмәт. Динне акча эшләүгә әйләндереп калдырырга кирәкми. Дин – кешенең әдәп-әхлагын югарыга күтәрү өчен бирелгән әйбер. Мәет юу җиңел эш түгел. Моның өчен акча сораучы да нәфесен белергә, нинди гаиләгә килүен аңларга тиеш, әлбәттә. Сорап алмаса, тагын да әйбәт. Әмма сорарга хакы бар. Зиратка әйләнеп кайтсак, гүр сәдакасы дигән әйбер, гомумән, юк. Кем сорап ала, шул оятсыз. Андый сәдака юк динебездә. Акчасы булмаган килеш, кредит алып, бурычка кереп, ашлар үткәрүнең дә кирәге юк. Мөмкинлеге бар икән, ул аңа авырлык тудырмый икән, үткәрсен. Кешедән яхшы түгел, дип кенә, бурычка кереп, аш уздыру дөрес түгел. Иң яхшысы үзе «бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим» дип, «лә илләһә иллаллаһ» дип әйтеп кулларын күтәреп дога кылса, мең тапкыр яхшырак. Биеп, җырлап, артистлар чакырып, фәлән бәйгә туй үткәргәндә, беркем дә акча санамый. Ә мәетне җирләгәндә сораган 5 мең сумнан зарланып әллә кайларга барып җитәләр.

Белгеч сүзе

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– Мәетләрне җирләүгә бәйле мөнәсәбәтләр РФнең 12.01.1996 елгы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, шулай ук РФ субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән көйләнә. Аның нигезендә, һәр кешегә үлгәннән соң, аның ихтыярын исәпкә алып, җирләү гарантияләнә. Ләкин кайбер шартлар бар. Беренчедән, җирләү ниятләнгән урын нормаларга туры килергә тиеш, кешене йортның ишегалдында яки басуда күмү тыела. Икенчедән, зиратта урыннар булырга тиеш. Каберләрне теләсә кайсы тәртиптә яки теләсә кайда казырга ярамый, бу билгеле бер тәртип буенча эшләнә. Әгәр шартлар үтәлсә, кешене илнең теләсә кайсы торак пункты зиратында җирләргә мөмкин. Җирне сатып алырга кирәкми, әмма җирләүгә бәйле ритуаль хезмәтләр түләүле башкарыла ала. Гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясен җирле үзидарә органнары билгели.

Көянтәсезләр

Көянтә-чиләкле авыл күптән үткәндә калды. Шушы юлларны яздым да каралтыны бер әйләнеп кердем: юк, бездә дә калмаган икән. Әле бу елларга кадәр саклаган бердәнбер көянтәне дә тапмадым, кирәге калмады дип ташлаганбыз, ахры. Инде авылда көянтә күрмәгән, аның нәрсә икәнен белмәгән тулы бер буын үсеп килә.

Бер көнне таныш укытучы көлдерә: «Көянтәчиләк дип сөйли идем, дүртенчеләрем: «Апай, көянтә нәрсә соң ул?» – дип сорыйлар. Башта аптырап калдым. Аннан соң, кулларымны җәеп күрсәтеп, көч-хәл аңлаттым», – ди. Ярар, әле чиләкнең нәрсә икәнен беләләр бит, дим. Сөйләшә торгач, авылда бүгенге балалар күреп, танып белмәгән әйберләр шактый булып чыкты: табагач, кыскыч, кисәү агачы... – болары зур мичләр белән бергә югалган, кулланыштан төшеп калган әйберләр генә. Аларга әле чыбыклы радионы, тәлинкәле патефон-радиоалгычларны, инде аудио-видеомагнитофоннарны, тагын әллә ниләрне өстәп булыр иде. Замана бик тиз үзгәрә, яңалыклар ташкын булып агыла, булганнары авылларга яшен тизлегендә килеп җитә.

Бүген авыл тормышы шәһәрнекеннән әллә ни калышмый. Көянтәне күрмәсә дә, авыл баласының да хәзер белмәгәне юк. Шунысы гына бар: алар күп әйберне рус телендә генә белә (кайчакта гади генә әйберләрне дә русча әйтәбез, аннан соң гына аңлыйлар, ди кайбер әти-әниләр). Аптырыйсы да түгел бугай: хәзер бакчага йөрүче авыл сабыйлары да үзара русча гына сөйләшә. Алар әле кукла-мяч дип кенә сөйләшсә дә аптырамас идең, фикерләрен эзлекле итеп, җөмләләрен дөрес итеп төзеп сөйләшә, телләрендә терминнар да шактый. Ә үсә төшкән саен нәрсә булып бетәр? Әнә татар телендә укытыла торган фәннәрне дә укытучыларыннан рус телендә аңлатуны сорыйлар, диләр бит.

Хәер, сүзебез көянтә турында иде бит әле. Көянтәләр... Алар безнең балачактан алып үткән гасырның туксанынчы елларына кадәр, өч дистә еллар җилкәдән төшмәде. Һәр хуҗалыкта иң кирәкле, иң кадерле эш коралы иде алар. Турая күрмәсеннәр дип, үзләрен коры урында, ел саен буяп, бик кадерләп саклыйсы иде. Аны һәркем үзе ясый алмый, каяндыр китереп саталар. Барысы да җилкәгә «ятышлы», уңайлы булмый. Су ташый-ташый, җилкәдә йөри-йөри генә аның эчке ягы шомарып бетә, көне буе су ташысаң да, җилкәне кырмый, авырттырмый башлый иде.

Безнең чорда 4–5 яшьләрдәге баланың инде үз көянтәсе була. Кибеткә кайткан хәлвәдән бушаган 3–5 литрлы калай чиләкләргә «колак тишеп», шуңа тимер чыбык бәйләп, чиләк ясап бирәләр. Ул яшьләрдә әзер кибет чиләге аскан бала сирәк була иде. Ел әйләнәсе суны эчәргә дигәнен – чишмәдән, калганын Шушма елгасыннан ташыйсы иде. Сүз уңаеннан, суы эчәргә яраклы чишмә шактый читтә булгач, безнең авылга читтән кияүгә кыз бирергә дә авырсынганнар хәтта. Аннан инде колонкалар куелгач, аларда чират торып, шыпырт кына өлкәннәр сөйләгәннәрне тыңлап, су ташулар бик тә рәхәт, күңелле булып истә калган. Кышын чиләкләр бозланып ката, аларны өйгә кергәч, табак-табаларга утыртып җебетәсе... Ә яздан көзгә кадәр Шушмадан мал-туарга эчертергә, яшелчәләргә сибәргә су ташыйсы иде. Авырсынмадык та, арымадык та. Үргә каршы су ташуны өлкәннәр балалар өчен авыр эш дип уйлый да белмәде. Су сипкәннән соң мичкә-савытларны да, булган барлык чиләкләрне дә тутырып куясы иде. Шуңа күрә әниләр зур чиләкләр белән ташымаска кушсалар да, алар күрмәгәндә, барыбыз да чиләкнең зуррагына үрелә идек, савытларны тизрәк тутырып бетереп, уенга чабасы килгәндер инде...

...Көянтәле балачак, яшьлек еллары белән бергә көянтәле авыл да хатирәләрдә генә калган шул инде. Көянтәләр зур югалту түгел, иң мөһиме, нигезләр бушамасын, авыллар югалмасын.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КӨТМӘГӘНДӘ

ТАТАРСТАНДА МАЛ ӨЧЕН ДӘ, КЕШЕ ӨЧЕН ДӘ КУРКЫНЫЧ ЧИР ТАБЫЛГАН



shutterstock.com

Яңа Чишмә районындагы фермер хуҗалыгында бруцеллез авыруы табылган! Терлекләр арасында очрый торган иң мәкерле инфекцияле чирләрнең берсе санала ул. Бруцеллез турында ишеткәч, кайберәүләр: «Маллар авырмый тормый инде алар», – дип кул селтәр. Әмма белгечләр чаң суга: терлекләр арасында очрый торган башка чирләрдән аермалы буларак, монысы кешеләргә дә йога һәм бик аянычлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин!

Сыерлар юк ителәчәк

Җәй азагында Яңа Чишмә фермеры Николай Скоковның хуҗалыгында бер-артлы үле бозаулар туа башлый. 18 август көнне бу хакта районның ветеринария идарәсенә хәбәр итә ул. Маллардан анализ алалар. Пробаларны бер генә түгел, икешәр тапкыр тикшерәләр. 1 сентябрь көнне фермерга аяктан егарлык хәбәр җиткерәләр: аның хуҗалыгындагы малларда бруцеллез чире табылган! Тәҗрибәле фермер алга таба ни көтәсен бик яхшы аңлый. Закон нигезендә әлеге чир табылган хуҗалыктагы барлык мөгезле эре терлек юкка чыгарылырга тиеш. Ә Скоков хуҗалыгында барлыгы 755 баш (!) мөгезле эре терлек исәпләнә. Шуларның 286сы – савым сыеры.

Татарстанның Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин сүзләренә караганда, хуҗалыктагы авыру сыерларны Дагыстандагы махсус оешмада юк итәчәкләр. Чир йоктырырга өлгермәгән сыерларны үзебездә суячаклар.

– Фермер хуҗалыгында атлар да бар. Алар аерым абзарда тора. Шуңа күрә атларга кагылмаячакбыз. Хуҗалыкта 1 сентябрьдән карантин кертелде. Закон нигезендә, 15 көн эчендә аннан бөтен мал чыгарылып бетәргә тиеш. Барлык чистарту, зарарсызландыру эшләре тәмамлангач, карантин бетереләчәк. Фермер юкка чыгарылган сыерлар өчен компенсация алачакмы-юкмы? Монысын инде Татарстан Хөкүмәте хәл итәчәк. Башта барлык чараларны тәмамлыйк әле, аннары билгеле булыр, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Еллар буе җыйган малын бер мизгелдә югалткан фермерның хәлен чамалавы кыен түгел. Ни эшләргә җыенганын белешергә теләп шалтыраткач, хәтта сөйләшергә дә теләмәде.

Кагылырга да ярамый!

Республиканың Баш ветеринария идарәсендә, гаеп фермерның үзендә булырга тиеш, дип фаразлыйлар. Габделхак Мотыйгуллин сүзләренә караганда, әлеге инфекция хуҗалыкка бруцеллез киң таралган төбәктән берниндиидокументсыз гына маллар алып кайту аркасында эләккән булырга мөмкин.

– Республикада малларны ике тапкыр – яз һәм көз көннәрендә бруцеллезга тикшерәләр. Хәзер дә шул эшләр бара. Ике тапкыр тикшергәндә дә күренмичә, аннары кисәк кенә чир пәйда була алмый бит инде, – ди ул.

Әлегә бу фаразлар гына, билгеле. Әмма шунысы төгәл билгеле: бу чир республикага үтеп кергән, һәм аны тиз арада юкка чыгарырга кирәк.

Бруцеллез турында сүз чыккач, соңгы тапкыр бу чир республикада моннан 30 ел элек табылган дигән хәбәр таралган иде. Ветеринария идарәсендә исә бу уңайдан да ачыклык керттеләр: соңгы тапкыр бруцеллез чире 2011 елда Чүпрәле районының Алешкин-Саплык авылы янында урнашкан дуңгызчылык хуҗалыгында табылган булган. Ул вакытта эшләр зурга китмәгән, чир таралуны туктатып кала алганнар. Габделхак Мотыйгуллин, быел да шулай булачак, дип өметләндерә.

– Хәзер бу хуҗалыкка тулысынча юл ябык. Аннан мал да, ит тә, сөт тә алып булмый. Димәк, башкаларның малларына, шул исәптән кешеләрнең үзләренә дә куркыныч янамый. Бу чир кешеләргә дә йога ала бит. Шуңа күрә авыру сыерның сөтен эчәргә ярамый, – ди ул.

Моннан тыш ул кешегә авыру хайванга кагылганда, астын чистартканда хәтта эш кораллары аша да йога ала. Бер терлектән икенчесенә исә күбрәк һава юлы, терлекнең җенес әгъзаларының лайлалы тышчасы аша күчә. Әлегә чирнең инкубация чоры 2–4 атна.

– Бруцеллез йоктырган буаз сыер, гадәттә, үле бозау китерә. Бу – әлеге чирнең иң төп билгеләренең берсе. Башка очракларда ул берниндибилгеләрсез генә уза. Шуңа күрә үле бозау туса, шикләнерлә җирлек бар. Аны тиз арада лабораториядә тикшерергә кирәк, – дип киңәш бирә Габделхак Мотыйгуллин.

Кешене дә ега

Авыру терлектән кешегә йокса да, бруцеллез кешедән кешегә иярми. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсенең территорияләрне санитар саклау бүлеге белгече Регина Әфләтүнова шулай дип ышандыра.

– Кеше өчен аеруча куркыныч авыру бу. Баштарак ул үзен берниндибилгеләр белән дә сиздермәскә мөмкин. Чир акрынлап кына тамыр җәя. Аннары кешенең буыннары, бигрәк тә аяклары сызлый башлый, ул гел тирли, тәнен бизгәк тота, хәлсезлектән тилмерә. Шуңа күрә бу билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – ди белгеч.

Регина Әфләтүнова сүзләренә караганда, мәкерле чир акрынлап кешенең барлык органнарын зарарлый. Бруцеллез бигрәк тә йөрәк, үпкә, ашкайнату, терәк-хәрәкәт аппараты, нерв һәм кан тамырлары системасына «бәрә». Ул хәтта менингит (баш һәм арка мие тышчасы ялкынсыну), артрит (сөяк, буыннар кәкрәю) китереп чыгарырга мөмкин.

Күреп торабыз: соңгы арада кешеләрнең генә түгел, терлекләрнең дә авырудан башы чыкмый. Маллар арасында да әле бер, әле икенче чир табылып кына тора. Габделхак Мотыйгуллин моның төп сәбәбен ваемсызлыгыбызда күрә.

> – Уаулыкны беркайчан да югалтырга ярамый. Тавык-чебеш, мал-туарны документсыз сатып алырга ярамый. Аларның ветеринар белешмәсе булырга тиеш. Алыпсатарлардан да иң элек әнә шуны сорарга кирәк. Арзан хакка алданып, билгесез җирдән, кешедән мал сатып алырга ашыкмагыз, – дип кисәтә идарә башлыгы урынбасары.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӘНИ, МИН ИСӘН!

Аның исән каласына табиблар да ышанмый. Футбол уйнаганда тәгәрәп киткән туп артыннан чапкан бала трансформатор будкасына килеп керә. 10 яшьлек малайны ток суга: көчәнеш 10 мең вольт була. Күз алдына китерүе дә куркыныч. 2021 елның июль аеН әле дә күз яшьләрсез искә алып булмый, ди малайның әнисе.

– Без Башкортстанның Туймазы районындагы Балтай авылында яши идек. Улым Илназның бәлагә тарыганын ишетүгә, йөрәгем туктап калгандай булды. Бик авыр кичердем. Ул бит минем 42 яшемдә тапкан балам. Бик кадерләп, яратып кына үстердек без аны. Барыбыз да бер теләктә идек – Илназ гына исән калсын! Шөкер, Аллаһы Тәгалә безне ишетте. Табиблар да бу очракны могҗизага тиңләде, – ди Зөлфия ханым.

Илназ – гаиләдә җиденче бала. Әнисе берүзе генә үскәч, балачактан, ишле гаиләм булачак, дип хыяллана. Кияүгә чыксам, күп итеп бала алып кайтыр идем, ди ул. Теләге тормышка аша. Ире Марат белән алар биш балага гомер бирәләр. Ә ике кызларын тәрбиягә алалар.

– 21 яшемдә кияүгә чыктым. Башта кызым туды, аңа хәзер 32 яшь. Ике елдан тагын улыбыз туды. Аннан соң игезәк ир балалар таптым. Бик тә кыз балалар үстерәсем килгән иде. Олыгаеп барганда кыз булмасмы дип, тагын бәби алып кайтырга булдым. Илназым туды. Шуннан соң да кыз бала үстерәсе килү теләгем кимемәде. Ирем белән уйлаштык та тәрбиягә кыз алырга булдык. Башта берсен алып кайттык. Ул баланы әнисе тапкан да ташлап калдырган. Без алганда аңа 6 яшь иде. Күп тә үтмәде, бу балага тагын иптәш эзли башладык. Бөтен Россия буенча эзләдек без аны, – дип сөйли Зөлфия ханым. – Ике атна узды микән, опека бүлегеннән шалтыраттылар. Бер бала алып килделәр, килеп карагыз, диделәр. Бу кызның әти-әнисе үлгән, әбисе, карый алмыйм дип, ятимнәр йортына тапшырган. Бик сөенеп алып кайтып киттек без аны. Ул балаларның бездә яшәүләренә 10 ел була инде. «Әти», «әни» дип кенә торалар. Бик яратабыз аларны.

Гаиләләренә сынау килгәч, алар аны бергә күтәрә. Бөтенесе бердәм булып, Илназларының гомере өчен көрәшә. Ул чакларда илдә коронавирус котырган вакыт. Зөлфияне сабые янына кертмиләр дә, аны күрсәтмиләр дә.

– Илназым 12 көн реанимациядә булды. Минем хәлемне белсәгез иде. Беренче көннәрдә үкереп-үкереп еладым. Шашар дәрәҗәгә җиткән идем. Өйдә үзем генә. Бер мәлне әллә ни булды миңа. Тормыш икегә бүленеп, мин яңасына атладым. «Елап утырып, балаңа ничек ярдәм итмәкче буласың? Тынычланмыйча, ничек улың терелсен?!» – дидем үземә. Дөньям яктырып китте. Мин көчле булырга сүз бирдем, – ди Зөлфия.

Улы белән очрашу аңа тагын да көч өсти. Илназны палатага чыгардык, килегез, дип чакыргач, ничек кулсыз калуын аңлатырмын дигән ананы улы елмаеп каршы ала. «Әни, мин исән! Ничек тә яшәрмен әле», – ди ул. Зөлфиягә шул сүз җитә.

– Илназ болай да акыллы сүзләр күп сөйли иде. Үлем белән күзгә-күз очрашкач, кечкенә булса да, яшәүнең мәгънәсен аңлаган ул. Бер дә сер бирмәде, – ди ул. – Илназның башта кул чукларын гына кискәннәр иде. Кулы озак төзәлмәде. Табиблар, терсәктән югары кисмичә булмый, диделәр. Ризалашмыйча, нишлисең?! Иң авыры кулларын кисәргә операциягә озату булды. Үзенә әйтмәдек. «Яраларыңны бәйләп кенә куячаклар», – дип ялганладык. Кайдан көч тапкандыр, әле дә шаккатам.

Өенә кайткач, Илназ социаль челтәрләрдә утыра башлый. Аны күреп сокланучылар арасында танылган кешеләр дә була. Шулай итеп, язылучылар саны арта. Кулына протез алганда да шул мәрхәмәтле дуслары ярдәм итә дә инде аңа.

Гаилә архивыннан

– Протез алырга дип барсак, бер ел көтәргә кирәк, дип кайтардылар. Баланың да күңеле төште. Шунда безгә Татарстан, Башкортстан җырчылары, блогерлар, акча җыеп карыйк, диделәр. Ризалашмый чарам юк иде. Илназга кирәкле «куллар» 3 миллион 600 мең сум тора. Күрше авыл егете җырчы Ришат Төхвәтуллин да ярдәм итте. Шулай итеп, ике атна эчендә кирәкле сумма җыелды. Илназ протезны кияргә дә, кулына әйберләр тотарга да, спорт белән шөгыльләнергә дә өйрәнде. Тик тиз үсеп китте. Яңадан протезлар ясатырга кирәк. Анысын инде дәүләттән бирәчәкләр. Тиздән киеп карарга барачакбыз, – ди әнисе. – Улым кечкенә, куллары ябык. Ә протез бик авыр. Шулай булса да, куллы булыр өчен бик тырыша ул. Табиблар, Илназ үсә төшкәч, яңачарак, уңайлы протез булачак, дип ышандыра.

Илназ бик актив. Гаиләсе аны укытыр өчен авылдан Туймазыга күченгән. Атнага бер генә көн дә ял итми икән. 5 көн буе җиңел атлетика буенча күнекмәләргә йөри. Күптән түгел Бөтенроссия ярышларында катнашып, терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган балалар һәм үсмерләр арасында 100 метрга йөгерүдә беренче килгән. Атнаның ике көнендә Казандагы бер онлайн мәктәптә укый.

– Язмыш ничек кенә сынаса да, сынауны кабул итәргә кирәк. Иң мөһиме – коткыга бирелмәгез. Әниләргә киңәшем шул. Балагызга ышаныгыз, аны үсендереп торыгыз, – ди Зөлфия. – «Ватаным Татарстан» аша Илназга протез алырга акча җыйган кешеләргә рәхмәт җиткерәсем килә. Бөтен ил белән ярдәм иттеләр. Чит илләрдән шалтыратып, 100әр мең сум акча салучылар булды. Күңелемне иң тетрәндергәне – улыма кечкенә балалар да акча салдыртты. Бер әни шалтыратты. Кечкенә кызы, акча саклый торган копилкасын ваттырып, Илназга бирергә кушкан. Андый балалар күп булды. Мин аларны гел исемдә тотам. Исән-сау булсыннар. Сәламәтлекләре нык булсын. Безнең гаиләгә килгән хәсрәтне бергә күтәргән һәркемгә бик рәхмәтлебез.

ВЕНЕРА ХӘСӘНОВА: *«Үпкәләгән чаклар да бар»*

Венерага туганда ук ДЦП диагнозы куялар. Хәзер аңа 46 яшь, Лаеш районының Кече Елга авылында яши ул. Шөкер, Венера үзен-үзе йөртерлек хәлдә. Кирәк икән, ашарга да әзерли, тегә, бәйли, картиналар ясый, әле хәтта шигырьләр дә яза. Боларның барысы өчен дә әти-әнисенә рәхмәтле.

– Алар мине кулдан килгәнчә дәваларга тырышты. Күрсәтмәгән табиблары калмады, тернәкләндерү үзәкләренә күп йөрдек. Шуңа күрә мин әти-әниемә гомерем буе рәхмәтле, – ди Венера. – Кая гына йөрмәдем, нинди генә хәлдәге кешеләрне күрмәдем. Зарланасы килгән чакларда аларны уйлыйм, күз алдына китерәм.

Венера – гаиләдә икенче бала. Апасы Алсу, сеңлесе Эльмира бар. Аларның үз тормышлары инде. Шулай булса да, Венерага гел ярдәм итеп торалар. Туганнарның җылы карашы яшәргә көч бирә дә инде, ди ул.

– Әтием бер ел элек үлеп китте. Исән булса, аңа быел 73 яшь тулган булыр иде. Хәзер әни белән икәү генә калдык. Әниемә дә 70 яшь инде. Шулай булса да, ул мине әле дә сабый баладай карый. Әни барда мин бәхетле, – ди ул. – Кайчандыр йөрү түгел, хәтта утыра да белмәгәнмен бит мин! Бака кебек сикергәнмен. Әни тырышкан, ничек итсә иткән, мине аякка бастырыр өчен бар көчен куйган. Табибларга да рәхмәт. Күнегүләр ясагач, дәвалану алгач, мин акрынлап йөри башладым.

Кечкенә чагында Венерага операция ясамакчы булалар. Табиблар алдан кисәтә: аякка басарга да мөмкин, әмма урынга калуы да бар. 12 яшьлек бала икенчесеннән курка һәм операциядән баш тарта.

– Урынга калып, кешедән ярдәм сорап ятудан курыктым. Ничек язган, шулай булыр, дидем. Әмма кайчак язмышыма үпкәләп тә куям. Минем иптәшләрем гаиләле, йөгереп йөриләр, дим. Авыру булганыма күңелем төшә. Аллаһы Тәгаләдән узып булмый. Үземне ничек бар шулай кабул итеп, яшәвемне дәвам иттерәм. Бәлки мин аяклы-куллы, сау-сәламәт кешеләрдән бәхетлерәктер дип тә уйлап куям, – ди Венера.

Авылдагы өйләрендә Венера өчен барлык шартлар бар. Шәһәрдәге кебек шартларда яшибез, ди ул. Венера, аяклары авырткач, коляскада гына йөри икән. Ә ул бик авыр. Әтисе вафатыннан соң, әнисенә мәшәкать арткан. Шөкер, мәрхәмәтле кешеләр очрап тора үзләренә. Авылдашлары коляска белән урамга чыгып йөрер өчен пандус ясап биргәннәр.

– Йөри алмыйм, дип, тик утырганым юк. Ашарга да пешерәм, бәйлим дә. Күп вакытым алмаздан картиналар ясап уза. Шулай итеп, күңелгә рәхәтлек табам. Мин авыру, дип утырып булмый инде. Шулкадәр тиз үтә гомер. Шуңа да һәр мизгелнең кадерен белеп яшисем килә. Сау-сәламәт кешеләргә дә киңәшем шул.

Гаилә архивыннан

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ВАДИМ ЗАХАРОВ: «ПОПУЛЯРЛЫКНЫ КҮТӘРӘ БЕЛЕРГӘ КИРӘК»

Тамашачы аны ихласлыгы өчен якын итә. Сәхнәдә дә, тормышта да эчкерсез, гади ул. Татарстанның атказанган артисты Вадим ЗАХАРОВ белән «йолдыз чире» белән авыручылар арасында «кайнап» та, бу сыйфатларны саклап калу, тормыштан канәгать булу һәм мәңгелек яра турында сөйләштек. Җырчы өчен сөйләшә белү мөһимме? Шәһәр баласы авыл турында җырлый аламы?

«Мин – йолдыз» дип йөрергә хакым юк

:: Яшерен-батырын түгел, бүген татар эстрадасында түшәмнән югары сикерүче, танылу өчен барына да әзер булган җырчылар шактый. Нигә аларга игътибар итмиләр дә тыйнак кына басып җырлаучы Вадим Захаровны яраталар?

– Кем белгән инде аны… Холык-фигылем шундыйдыр. Бәлки, сөйкемле сөягем бардыр. Минем җырларны сикерә-сикерә җырлап булмый бит. Ә сәхнәдә үзеңне җырларыңа туры китереп тотарга кирәк. Андый образ күңелемә дә ятмый. Барына да әзер җырчыларга килгәндә, артыгы кирәкми, булганына канәгать кеше мин. Ә андый кеше бәхетле була.

:: Уңыш сере – гадилектә, дип тә әйткәнегез бар. «Йолдыз чире» таралган заманда бу сыйфатны ничек саклап калырга соң?

– «Йолдыз чире»н беркайчан да тойганым булмады. Гомумән, «мин – йолдыз» дип йөрергә хакым юк дип уйлыйм. Ул дәрәҗәгә җитү өчен иҗатың бик күпләрне колачларга тиеш. Аннан соң, яшьтән үк борын күтәрергә ирек бирмәделәр. Гаиләдә дә, иҗат юлымны башлаганда да. Тәрбияле, зыялы, итагатьле җырчылар белән эшләргә насыйп булды. Зөһрә апа Шәрифуллина миңа гел: «Вадим, үзеңне кулда тот. Популярлашып киткән вакытларың булыр, сизми дә калырсың», – дип әйтә килде. Андый кешеләр тәрбиясен алуым белән мин бик бәхетле.

> Популярлыкны, байлыкны күтәрә дә белергә кирәк бит әле. Ә аны күпләр күтәрә алмый. «Йолдыз чире» дә шуннан барлыкка килә.

:: Авыл турындагы җырлар аеруча моңлы була, әйеме? Ничек уйлыйсыз, шәһәр баласы авыл турында җырлый аламы?

– Алар да ничек тә булса авыл белән бәйледер, юктан гына авыл турында җырлыйсылары килмидер инде. Ләкин җырлау – бер нәрсә, үзең аша үткәреп, тамашачы күңеленә җиткерү мөһимрәк. Аннан соң, җырлар гына түгел, иң моңлы җырчылар да авыл җирендә туадыр дип уйлыйм. Шәһәр балаларын кимсетәсем килми, әлбәттә. Әмма авылның һавасы да, суы да, урманнары, табигате дә – башка ул.

:: Гомумән, үзең кичермәгән хисләр, үзең башкармаган гамәлләр турында җырлауга ничек карыйсыз?

– Мәсәлән, бар сагышлы җырлар. Кайгы-хәсрәт берәүне дә читләтеп үтми – ул хисләр һәркемгә таныш. Шул ук вакытта балаларын, тормыш иптәшен ташлап китеп, «сөйгәнеңне ташлама», «башка ярга карама» ише җырлар җырлаучылар бар. Менә андыйларны мин бөтенләй аңламыйм. Сәхнәгә чыгасың икән, син тамашачыга нинди дә булса фикер җиткерергә, үзеңне акыллы итеп хис итәргә тиеш. Җырларыңдагы сүзләреңә үзе үк каршы килгән кеше тамашачыга нәрсә өйрәтә алсын да ул хисләрне күңеленә ничек сеңдерсен инде?

«Татар-информ»

«Җырчы сөйләшә белергә тиеш»

:: Ә сез җырларны ничек сайлыйсыз?

– Җырны алып укыйм я тыңлыйм да, ошаса, җырлыйм, ошамаса, юк. Иң беренче чиратта, минем күңелгә үтеп керергә тиеш ул. Беркайчан да, тамашачыга ошасын әле, хит булсын әле, дип җырлаганым юк. Ахыр чиктә, тамашачының да күңеленә хуш килә ул.

Җырлар бик күп килә, әмма барысын да җырлап бетереп булмый. Җырларын алмаганга үпкәләүчеләр дә була хәтта. Сүзләренә аеруча таләпчән мин. Әдәбиятка, татар теленә мәхәббәт кечкенәдән килә. Шуңа азмы-күпме нәрсәнең нәрсә икәнен аңлыйм. Безне әдәбияттан Харис Миңнегалиевич укытты. Кайвакыт аның дәресенә шигырьләрне сыйныфташлар арасында берүзем ятлап килә идем. Ятламаган очракта, «Захаров, чирегеңә «берле» дә чыгармыйм», – дип әйтә иде. Ул сүзләр бәгырьгә сеңеп калган.

:: Яраткан авторларыгыз бармы?

– Фәнис Яруллин, Әнгам Атнабаев шигырьләрен яратам. Аларның берничә җыры репертуарымда да бар. Соңгы арада Айдар Минһаҗев язган җырларны еш башкарам. Аның сүзләре, Айдар Тимербаев көенә язылган 17ләп җырым бар.

:: Җырчы белем эстәүдән, камилләшүдән туктамаска тиеш дигән фикер белән килешәсезме?

– Укып кына җырчы булып булмый. Тавыш, талант – беренче урында. Әмма җырчыга укырга кирәк. Кабатлап әйтәм: син тамашачыга ниндидер фикер җиткерергә тиеш. Моның өчен сөйләшә белергә дә кирәк.

> Кызганыч, эстрадада сөйләшә белмәүчеләр җитәрлек. Сәхнәгә чыгып, ниндидер «дежур» сүзләр әйтәләр дә бетте. Ә бит тамашачы белән аралашканда аның күңелендә ни дә булса калдырырга кирәк.

Блиц-сораштыру

– Ялгышмасам, сез фонограммага бөтенләй җырламыйсыз. Бу – принципмы?
– Мин каршы ул әйбергә. Фонограммага җырлап, кешенең күңелен «селкетеп» булмый.
– Җаныгыз ял итә торган урын?
– Җан дуслар янында.
– Хәзер күп кенә гаиләләр «икебез дә – бертигез» кагыйдәсе белән яши. Сезнең гаиләдә ничек?
– Икең дә бертигез була алмыйсың инде ул. Ләкин икеңнең дә фикере, ул фикерне җиткерергә мөмкинлеге булырга тиеш.
– Ике кыз бала үстерәсез. Нинди әти сез?
– Бик йомшак. Балаларны яратырга кирәк. Әти каеше булырга тиеш тиешен. Ләкин хатын миңа караганда кырысрактыр ул *(көлә)*. Балаларга бер нәрсәне кызганган юк. Артык иркәләү түгел, кешенекенә кызыкмасыннар дип тырышабыз.
– Иң зур хыял?
– Ике кызымны да яхшы ир-ат кулына тапшырып, туйларында өстәл суга-суга: «Кызларыма бер генә начар сүз дә әйтәсе булмагыз», – дип теләк телисем килә.

:: Башка җырчылар турында бик сак сөйлисез. Ләкин шул ук вакытта концертыгыз «Шоу түгел, концерт» дип атала…

– Мин бик каты бәрелеп тә сөйли алам, ләкин кемнедер кимсетергә хакым бар дип уйламыйм. Ә концертка килгәндә, хәзер бөтенесе шоу ясарга тырыша бит. Моның өчен шоумен булырга кирәк. Мин дә, җырларым да андый форматка туры килми. Концертларыма уйланып, моңланып, көлешеп утырырга чакырам.

«Мендәргә капланып елаган чаклар да булды…»

:: Сезне кайсы җырыгыз танытты?

– Бу сорауны тамашачыга бирсәк, кемдер, бөтен җырыгызны да яратабыз, дияр. Кемдер «Көттермәсәк иде әнкәйләрне» яки «Урамнар буйлатып, гармуннар уйнатып» җырын атар. Берсен генә өздереп атый алмыйм.

:: «Көттермәсәк иде әнкәйләрне» берәүне дә битараф калдырмагандыр, мөгаен…

– Ул чакта миңа зур-зур кешеләр шалтыратып, «Вадим, әнкәй көткән бит инде ул безне…» – дип өзгәләнде. Дуслар арасында да: «Кайтмагандыз, дурак булып йөргәнбез инде, әйә», – диючеләр күп булды.

:: Ир балалар әниләре белән бигрәк якын була ул, әйеме?

– Бик.

:: Ул җыр хәзер башкачарак яңгырый кебек…

– Әни үлгәннән бирле җырлый алмыйм мин аны. Бик сорагач, туры килә инде. Ләкин җырлаган саен авыр.

:: Елаганыгыз бармы?

– Көн саен елыйм. Кешегә күрсәтмим генә. Гел әни искә төшә, гел күңел тула. Мендәргә капланып елаган чаклар да булды. Ләкин безнең әни елый торган кеше түгел иде. Әни елап утырмас иде, дим дә үземне кулда тотарга тырышам. Вакытсыз китте ул. Җитеш һәм мул тормышның, балаларының, оныкларының рәхәтен күреп яши торган вакытта китте.

Иртән торуга, балконга чыгам да, зәңгәр һавага карап: «И, Ходаем, үлгән бәндәң Маринаның җанын тынычландыр», – дип сорыйм, үземә, гаиләмә исәнлек-саулык телим. Һәр көнем шулай башлана.

:: Авылга кайту авыррактыр хәзер?

– Кайтасы килә дә, килми дә. Тик кайтырга кирәк. Әнинең урынында бераз ятып торсам да, рәхәт булып китә. Мин аның җан биргәнен күрмәдем. Кукмарага дару алырга чыгып киткән идем. Дәресен генә әйткәндә, әнинең ничек үлгәнен күрмәсәм ярар иде, дип йөрдем мин. Шуннан әйләнеп кайтканчы, китеп барган. Табиблар әйткән фараз көне, вакыты белән туры килде…

:: Әтиегез?..

– Исән-сау. Ул көткәндә, туган якка кайту барыбер рәхәт.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

–1–

Көн-төн уйлады Галиб, көн-төн! Ләкин һич кенә дә уеның очына чыга алмады. Чүлмәк хәтле генә бәләкәй башында гүя меңләгән умарта корты гөжли иде. Шура әгъзалары белән киңәш-табыш итим дисә, шымчы Вәҗүд астан гына кисеп аяк чалачак. Ниһаять, бер әрсез уй күченнән аерылып лепкәгә «кунды»: нокта! Шунда тукталырга кирәк!

Ул өстәлдәге тартманың нәни төймәсенә бармак очын тидерде.

– Мирзам, кер!

Ярдәмчесе, ишек төбендә генә торган кебек, «ә» дигәнче каршысына килеп тә басты.

– Ни боерасың, бабам?

Галиб ярты бүлмәне биләгән тәсле экран өстендәге япманы идәнгә шудырды.

– Мин сиңа бабай түгел, мин – Остаз!

– Гафу, Остаз!

– Күк җисемнәренең хәрәкәтен һәрдаим күзәтәсеңме, Мирзам?

– Күзәтәбез, баб... Остаз! Тәртип!

– Тәртип, тәртип! – диде Галиб, үртәгәндәй. – Хаос дигән әшәке чир күк киңлекләренә дә йокты. Әнә кайбер иярченнәр отыры аза, бүтән җисемнәрнең коткысына бирелеп, үз сукмагыннан тайпыла. Күзәтүчеләргә җиткер: чарасын күрсеннәр!

Остаз телескопның сыңар күзенә текәлде. Йа Кодрәтле Аллаһ! Тудырсаң да тудырырсың икән шундый гүзәл сурәт! Галәм бизәкле яулык бөркәнгән чибәр кызга охшаган иде. Кайчакта сары, кызыл, аксыл йолдызларны җыеп уч төбендә җылытасы килә. Бу матурлык җуелмыйча мәңге-мәңге саклансын иде! Чү, күңел нечкәрде, ә аңа хисләнергә ярамый иде.

– Үгез йолдызлыгы соңгы арада артык нык кабына, яктысыннан күз сукырая хәтта. Сәбәбе ни? Тикшердегезме, Мирзам? Әллә үзен Кояш дип саташамы икән, очындык!

– Кораб юлладык, нәтиҗәсен көтәбез, Остаз.

– Адашкан йолдызларны да бераз тыярга иде. Галактика үзәгендә күпме карт, кырыенда күпме яшь йолдыз тезелгән, шуларның исемлеген яңартыгыз!

– Яңартырбыз, Остаз.

– Һәрнәрсә исәп ярата, Мирзам!

– Ярата, Остаз, ярата.

– Попугай төсле артымнан кабатлама, Мирзам! Мин әйткәннәрне колагыңа киртлә. Бөек Кодрәт безгә зур вазыйфа йөкләгән: миллионлаган планета арасыннан күзәтүче итеп сайлаган, бүтән тереклек ияләре белән чагыштырсаң, нәкъ менә безне генә зирәклек, җитезлек, тапкырлык ягыннан өстен куйган, нәкъ безне генә зиһен, акыл, сәләт белән бүләкләгән.

– Рас, Остаз, рас! Безнең белән ярышырлык, хәтта ки безнең белән тиңләшерлек бер генә җан иясе дә юк!

Галиб экранны япма белән каплады. Сүз озынга сузылды, ә аны кыскартмасаң, лепкәдә безелдәгән баягы «корт» очып китәргә мөмкин иде.

– Мирзам, без – Җир шарына иң якын урнашкан мәмләкәт. Гасырлар дәвамында без, ягъни центаврлылар, Җир төркеменә кергән Меркурий, Венера һәм Марс дусларыбыз белән тыныч кына яшибез. Юпитер, Сатурн, Уран һәм Нептун кебек гигантлар әллә кайчан аларны тузанга әйләндерер иде, бәс, бездән шүрлиләр, без ачулансакмы, без... – Тукта, тагын читкә авыша! Ярдәмчесен бөтенләй башка максат белән чакырган иде лә! – Җир димәктән, анда ни хәлләр икән, Мирзам?

Баягы тиргәлүдән айнымаган егет авызын гына ачкан иде, Галиб кисәтеп өлгерде:

– Дөресен генә сөйлә! Бизәкләмәчуклама!

– Нәрсә диим икән, Остаз... Дөнья яралганнан бирле анда сугышлар тынмый. Башта кыргый кабиләләр ук-җәяләрдән атышкан, аннан халык исәя-исәя балтасәнәккә, аннан утлы коралга ябышкан. Эволюция, Остаз! Бүген алар атом дип шашына. Илләр белән илләр бозылыша. Бер-берсенә яныйлар, бер-берсенең бугазын чәйниләр. Адәм – куркыныч зат, Остаз! Үзләре үк Җирнең көлен күккә очырмагае, дим. Киләчәк турында кайгырту юк. Галимголәмәләренең «мин-минлеге»нә шаккатарлык. Аң дәрәҗәләре искиткеч түбән. Космосны өйрәнәбез дип, махсус үзәкләр оештырганнар. Имеш, галәмдә тагын алар кебек акыллы җан иясе бар микән, тикшерәләр. Көлеп үләрсең, Остаз!

– Болар миңа күптән таныш, кичә генә тумадык, яңалыкларың искергән, Мирзам.

– Аптыраганнан әйтәм, Җирдә көн саен талаш, үтереш!

– Һе, аларны иманга китереп булырмы икән? Ахмак кына үзенә чокыр казый, – диде Галиб, өметсез тавыш белән. – Без дә гаепле. Беренчедән, вакытында ялгышларын төзәтмәдек, җае белән акылга килерләр дип өметләндек. Икенчедән, бүтән җисемнәр белән булашып, Җиргә игътибарны киметтек.

– Без аларны гел хәвеф-хәтәрләрдән саклыйбыз, ничә мәртәбә җәнҗалчы тышкы планеталар һөҗүменнән коткардык. Әллә кисәтү рәвешендә генә үзләрен әзрәк селкетикме, Остаз?

Хуҗа ярдәмчесенең җилкәсеннән шапылдатты:

– Тимә, бичара Җир болай да бик еш тетри.

– Кайсыдыр ки планета узынса, син кызганмыйсың, маңгаена чиертәсең, ә Җиргә нигәдер тел-теш тидертмисең, Остаз. Сәер!

– Мирзам! Бу безнең гәпнең кереш өлеше генә, инде уртасын-азагын тыңла. Борынгы хәритәдә Җирнең сул канатын биләгән татай улысы тамгаланган...

– Хәритә пыяла шкафта, кертимме? – дип ярдәмчесе урыныннан купмакчы иде, Галиб туктатты:

– Без аны хәтердән йомык күз белән дә укыйбыз. Син яшь, синдә элеккеге чорлар турында мәгълүмат аз, ә миндә – йөз дә егерме биш яшьлек картта ул тау хәтле. Заманында татай көчле дәүләт тоткан. – Хуҗаның күзе нурланып янды, ул шәкертенә дәрес биргәндәй дәртләнеп сөйләргә тотынды. – Бабалары батырларның батыры саналган, дошманына каршы яу чапканда атларның тоягыннан ут чәчелгән! Күкрәгендә арыслан тибенгән татайның! Ызгышталашларны өнәмәгән ул, таш кальгалар төзегән, сәүдә иткән, көмеш-алтын койган, чәчкән-урган, балалар үстергән, нәсел үрчеткән. Халык бәйсез булган, ирекле булган, үз көен көйләгән, үз җырын җырлаган. Ә бүген татай дигән кавем кем? Кул-аягы богауланган әсирме? Хокуксыз колмы?

Дәвамы бар >

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

СӨЛӘЙМАНОВА (АСЕЕВА) ФЛЮРА ЗЫЯТДИН КЫЗЫ

(10.03.1939–14.09.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Татарстан Республикасының халык артисты Сөләйманова Флюра Зыятдин кызы 14 сентябрьдә 85 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Флюра Сөләйманова 1939 елның 10 мартында ТАССРның Кама Тамагы районы Иске Барыш авылында дөньяга килә. Хезмәт эшчәнлеген, 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң, 1955 елда Казан шәһәре киез итек комбинатында штамповщик буларак башлап җибәрә. Бер үк вакытта кичке мәктәптә укый, үзешчән сәнгать белән шөгыльләнә: Горький исемендәге мәдәният йорты каршында композитор Сара Садыйкова оештырган һәм ул җитәкчелек иткән хорда җырлый.

Флюра Зыятдин кызы 1960 елда Казахстанга күченеп китә. Биредә ул Актүбә филармониясе, Казахстанның «Казахконцерт» дәүләт гастроль-концерт берләшмәсе җырчысы була. 1962–1966 елларда – Ульяновск өлкә филармониясе солисты.

Флюра Сөләйманова туып-үскән җиренә әйләнеп кайткач, башта Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә, шуннан соң ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында эшли. Бу чорда Флюра Сөләйманова башкарган әсәрләр радио фондына яздырыла.

1971–1991 елларда – Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең эстрада җырчысы. Шушы елларда Флюра Сөләйманова нигезен халык җырлары һәм татар композиторлары – Сара Садыйкова, Р. Яхин, З. Хәбибуллин, И. Шәмсетдинов, Ф. Әхмәтов, Җ. Фәйзи җырлары тәшкил иткән бик бай репертуарын булдырды. Аның башкаруында «Сахралар», «Урманнарда йөрдем», «Туйлар узгач», «Иртә дә генә торам», «Алтын-көмеш» җырлары, тамашачылар күңелен яулап, татар эстрадасының алтын фондында үзләренең лаеклы урынын тапты. Аның башкару осталыгы эчкерсезлеге, тирән мәгънәле булуы белән аерылып торды. Флюра Зыятдин кызы лаеклы ялга чыккач та Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә «Илһамият» ветераннар клубы әгъзасы буларак бик еш чыгыш ясады.

Флюра Сөләйманованың югары дәрәҗәдәге башкару осталыгы һәм намуслы хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «ТАССРның атказанган артисты», «Татарстан Республикасының халык артисты», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты. Флюра Сөләйманова 2023 елда «Республиканың Илһам Шакиров исемендәге премиясе лауреаты» дигән исемгә лаек булды.

Флюра Сөләйманова һәрвакыт яраткан эшенә иксез-чиксез тугрылыгы, зыялылыгы һәм изге күңеллелеге белән аерылып торды. Татар җыры сәнгатен саклау һәм үстерүдә үзеннән бәһаләп бетергесез өлеш керткән сөекле халык җырчысының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, В.Г. ШӘЙХРАЗЫЕВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН, Н.А. ВАЗЫЙХОВ, К.Н. НУРУЛЛИН

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе һәм республика парламенты депутатлары, Татарстан Республикасы халык артисты

СӨЛӘЙМАНОВА Флюра Зыятдин кызының

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмәнең якыннары һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Флюра Зыятдин кызының якты истәлеге тамашачылары күңелендә мәңгегә сакланыр.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы, халкыбызның сөекле җырчысы, Татарстанның халык артисты

Флера СӨЛӘЙМАНОВАның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмәнең туганнары, дуслары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Ходай Сезгә тирән хәсрәтегезне күтәрә алырдай көч, сабырлык бирсен! Сәнгатькә тугрылыклы дустыбызның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Блогерга киңәшләр

1 Интернетта блогны гади, аңлаешлы, халыкчан телдә алып барыгыз. Әмма ямьсез жаргоннарга төшеп бетмәгез.

2 Эмоцияләр белән уйнагыз. Социаль челтәр ул – хисләр дөньясы.

3 Контентның 90 процентында укучыга файда бирү мәслихәт. Һәм бары тик 10 процентын гына үз файдагызга кулланырга була. Мәсәлән, реклама эләргә.

4 Постларда үзегездән яратып кәләргә онытмагыз. Бу – кешене бизәүче сыйфат. Укучылар да аны ярата.

5 Лайк куярга, аккаунтка язылырга, пост белән бүлешергә сорагыз. Болар барысы да сезнең аккаунтны үстерә.

6 Постны сорау белән тәмамлагыз. Аралашуга чакырыгыз. Интерактивлык бик мөһим.

7 Сезгә язган комментарийларны җавапсыз калдырмаска тырышыгыз.

8 Укучыгызга якын булыгыз. Арагызда булган психологик киртәләрне җимерергә кирәк.

9 Үзегез өчен кыскача контент-план төзеп куйсагыз, уңайлы булачак. Кайчан, ничәдә, күпме һәм нәрсә эләчәксез. Темалар исемлеген булдырыгыз.

10 Башка блогерлар белән дуслашыгыз, алар белән коллаборация, уртак проектлар эшләгез.

Әз-мәз мәзәк

– Өч тиенгә җанын саткан, диләр андыйлар турында.
– Хәзер алай гына түгел инде, инфляция.

***

Бер ай отпуск аз тоелса, ике эштә эшләгез, икесендә дә ял бирерләр.

***

Психотерапевт:
– Үзегезне ничек хис итәсез?
– Миндә өмет юк инде... Үзегез ничек, доктор?

***

– Матурым, мин тазамы?
– Нәрсә сөйлисең син? Ул кадәр матур түгел бит инде мин.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: кан, култык, Раяз, Катмыш, вакыт, парад, бие, тармак, тели, Уяв, Ту, Алиш, канун, сызык, Ра, Ошо, Изаура, стар, Марк, ян, шаурма, Ми, алдану, чын, ата, Ка, за, тимер, Ниагара, тари, гив, ТНВ, Тын, өр, Тажетдинов, лайлач, сайлау, ут, нон, нигез, агач, та, тар.

Вертикаль: комак, ат, шаланда, рекорд, ала, карате, Динә, ки, Яуза, урау, Тура, Бунин, артист, Латвия, Анна, нам, Тямаев, ашыт, Войнич, кызык, суанит, влог, ак, шыттыру, мат, Анета, Таузар, ерылу, зар, Марина, Максат, ал, Айгөл, Кирам, Ира, Шариков.



Беләсең килсә...

1 Виктор Цойның атасының исеме ничек?
а) Тимур;
б) Роберт;
в) Артур.

2 Дөньядагы иң зәһәр борыч нинди?
а) Чили Инфинити;
б) Нага Вайпер;
в) Каролина Рипер.

3 Ультрамарин ул нинди төс?
а) кызгылт;
б) яшькелт;
в) зәңгәрсу.

4 Һади Атласиның әтисе кем булган?
а) мулла;
б) итекче;
в) сәүдәгәр.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. в); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 328

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булараk тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (**420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.**)

16+